**Татарстан Республикасы**

**Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе.**

**Удмуртия Республикасы**

**Ижау шәһәре Ленин районы “107 номерлы “Энҗе” балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе.**

***Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләре, башлангыч сыйныф укытучылары, студентлар өчен методик җыентык.***

# “Баш иябез сезнең алда!”




**Тирсә авылы.**

**2025 ел.**

Йосыпова Ләйсирә Наил кызы, Удмуртия Республикасы Ижау шәһәре 107 нче балалар бакчасы тәрбиячесе; Васильева Фәридә Мирсәет кызы, Гыйльманова Айсинә Рафис кызы, Шәйхиева Гөлсинә Мансур кызы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы МБМББУ Тирсә авылы "Миләүшә" балалар бакчасы тәрбиячеләре; Сабирҗанова Рәфинә Мөнәвир кызы, Әгерҗе районы Кырынды авылы мәктәп-балалар бакчасы тәрбиячесе; Рамазанова Гөлчәчәк Мөсәвир кызы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениесе Кадыбаш урта гомум белем бирү мәктәбе тәрбиячесе; Кавиева Лилия Фаат кызы, МБМББУ «Әгерҗе шәһәре 1 нче санлы "Алтын ачкыч" балалар бакчасының» алып баручы - логопеды; Гыйззәтуллина Эльвира Дәрсил кызы, МБМББУ «Әгерҗе шәһәре 8 нче санлы балалар бакчасының» татар телен өйрәтүче тәрбиячесе; Латыпова Алсу Рафаил кызы, Симакова Гөлнур Ильдус кызы, Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай урта мәктәбе башлангыч сыйныф укытучылары; Давлетшина Налия Нурулла кызы, Шавалиева Елена Василий кызы, МБМББУ «Әгерҗе шәһәре 1 нче санлы "Алтын ачкыч" балалар бакчасының» тәрбиячеләре; Газетдинова Резеда Исмәгыйль кызы, МБМББУ «Әгерҗе шәһәре 4 нче санлы балалар бакчасының» тәрбиячесе; Ягъфәрова Гөлназ Гамир кызы, Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авылы "Миләүшә" балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениесенең физкультура буенча инструкторы тарафыннан төзелгән мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләре өчен

## "БАШ ИЯБЕЗ СЕЗНЕҢ АЛДА!" МЕТОДИК ҖЫЕНТЫККА

**б ә я л ә м ә**

2025 ел - Бөек Җиңүнең 80 - еллыгы, тынычлык елы һәм нацизмга каршы көрәш елы һәм "Ватанны саклаучылар елы"дип игълан ителде. Ватанны саклаучылар елы-календарь датасы гына түгел, ә милли бердәмлек һәм патриотизм символы. Бу илебезнең суверенитетын һәм иминлеген саклаган һәм яклауны дәвам иткән кешеләргә тирән рәхмәт белдерү.

Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 80 ел узса да, сугыш хатирәләре, туган җиребезне, илебезне илбасарлардан саклап калган, аның иминлеге өчен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнарыбыз онытылырга тиеш түгел. Сугышның авыр җәрәхәтен иңнәрендә күтәргән хөрмәтле ветераннарыбыз бу афәтне мәңге үз хәтерләреннән җуймыйлар. Дәһшәтле еллар афәтен һәр гаилә кичергән. Күп аналар тол калган, улларын һәм кызларын югалткан. Тирән яра калдырган, йөрәкләргә әрнү салган ул сугыш. Күңелләр һаман сызлана, сыкрый әле.

Махсус хәрби операциянең беренче көннәреннән башлап безнең ватандашларыбыз, үз вакытында Рейхстаг түбәсенә Җиңү байрагын кадаган ата-бабаларыбызның данлы батырлык үрнәкләрен дәвам иттереп, җир йөзен

нацизмнан азат итә, озак көтелгән Җиңүне якынайта. Ватан өчен, киләчәк буыннарның имин тормышта яшәве өчен гомерләрен кызганмыйлар.

Балалар бакчасының төп бурычы — мөмкин кадәр иртәрәк балаларда туган җиргә мәхәббәт уяту, аларда үз иленең лаеклы кешесе һәм гражданы булырга ярдәм итәчәк характер сыйфатларын формалаштыру, туган йортка, балалар бакчасына, туган урамга мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү, ил казанышлары өчен горурлык хисе, армиягә мәхәббәт һәм хөрмәт, сугышчыларның батырлыгы өчен горурлык тәрбияләү.

Хәзерге мәгариф системасы мөгаллимнәр алдында гаять зур бурычлар куя: алар балаларны гадәттән тыш тыгыз уку материалы, белемнәр белән коралландырырга тиешләр, шул ук вакытта аларны шәхес буларак үстерү, күркәм әхлак сыйфатларын тәрбияләүдә, заман шартларына яраклашкан, дөньяда үз урынын табарга, тормышының барлык дәвамында үзбелемен күтәрергә, яңа күнекмәләрне үзләштерергә сәләтле булган кеше формалаштыруда да актив катнашырга тиеш. Бу җәһәттән укытучыларның һөнәри осталыгын арттыру, аларны яңа педагогик технологияләр, метод һәм алымнар белән эшләргә өйрәтү, шуның нигезендә балаларга белем һәм тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү Россия мәгариф системасынның мөһим бер шарты булып тора. Авторлар коллективы тәгъдим иткән әлеге методик җыетыкның максаты да бурычлары да бик төгәл итеп алынган: һәр төркемнең яшъ үзенчәлекләренә карап темалар дөрес сайланган. Методик кулланмада авторларның эш тәҗрибәсеннән үрнәкләр, шулай ук дәрестән тыш чараларны үткәрүгә караган материаллар тупланган.

Җыентыкта материаллар төрле чараларга багышланган. Дәрестән тыш эшләрдә белем һәм тәрбия бирү максатыннан чыгып эшләнгән. Тәкъдим ителгән әлеге ярдәмлектә чараларның күптөрле формалары кертелгән: истәлекләр, Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган сугыш һәм хезмәт ветераннары өчен чара, Бөек Җиңү турында балаларның сөйләм телен үстерү буенча педагоглар өчен семинар-практикум, ата-аналар, укытучылар һәм тәрбиячеләр өчен бәйрәмнәр, очрашулар, бәйгеләр һ.б.

Авторлар коллективы тарафыннан язылган җыентык әлеге төр кулланмаларга куелган таләпләргә туры килә, тәкъдим ителгән материаллар ватанпәрвәрлек кыйммәтләре нигезендә тәрбия бирүдә милли балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә, әти-әниләргә, башлангыч мәктәп укытучыларына, педагогик уку йортларында белем алучы студентларга зур ярдәмлек булып тора ала.

Рецензент: Казан федераль университетының
Алабуга институты, татар филологиясе
кафедрасы доценты,филология
фәннәре кандидаты________ Ә.С.Хәйруллина

КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
МИНИСТЕРСТВО НАУКИ И ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ЕЛАБУЖСКИЙ ИНСТИТУТ (ФИЛИАЛ) ФГАОУ ВО КФУ
ОГРН 1021602841381 ул. Казанская, д.89, г.Елабуга, 423604
ПОДПИСЬ
заверяю
Начальник отдела кадров и делопроизводства
КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ОТДЕЛ КАДРОВ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

**Баш мөхәррирләр:**

*Ягьфарова Г.Г.,* Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, мөдир.

*Йосыпова Л.Н.,* Удмурт Республикасы Ижау шәһәре Ленин районы “107 номерлы “Энҗе” балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, тәрбияче.

## ЭЧТӘЛЕК.


| | | |
|---|---|---|
| 1 | Аңлатма язуы | 4 |
| 2 | **“Сугышчан дан почмагы” акциясе конспекты.** *Гыйззәтуллина Эльвира Дәрсил кыз.* | 5 |
| 3 | **“Батырлар мәңге онытылмый” .**(*мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән Ватанны саклаучылар елы һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан чара) Давлетшина Налия Нурулла кызы,Шавалиева Елена Василий кызы.* | 8 |
| 4 | **“Сугыш кайтавазы һәм йөрәк хәтере”. (***Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган сугыш һәм хезмәт ветераннары өчен чара) Газетдинова Резеда Исмәгыйль кызы.* | 11 |
| 5 | **“Икмәк сере”** *(Балалар театры өчен сценарий) МБГУ Исәнбай урта мәктәбенең башлангыч класс укытучыларыСимакова Г.И., Латыпова А.Р.* | 14 |
| 6 | **“Онытылмас еллар”** *(Балалар театры өчен сценарий)МБГУ Исәнбай урта мәктәбенең башлангыч класс укытучылары Симакова Г.И., Латыпова А.Р.* | 17” |
| 7 | **“Кем безгә Бөек Җиңү яулаткан?” (***Бөек Җиңү турында балаларның сөйләм телен үстерү буенча педагоглар өчен семинар-практикум*) *Кавиева Лилия Фаат кызы.* | 21 |
| 8 | **“Күңелләрдә мәңге сакланыр”** *(Мәктәпкә әзерлек төркем балалары өчен) Рамазанова Гөлчәчәк Мөсәвир кызы.* | 25 |
| 9 | **«Онытылмады, онытылмас!»** *(Мәктәпкә әзерлек төркемендә Бөек Җиңүнең 80 еллыгы уңаенан шөгыль конспекты) Гыйльманова Айсинә Рәфис кызы* | 28 |
| 10 | **Э.Шәрифуллина “Минем бабай”.** *(Шигырь уку)Сабирзянова Рәфинә Мөнәвир кызы.* | 31 |
| 11 | **«Безгә тынычлык кирәк».** (*Катанаш төркем балалары өчен эшчәнлек конспекты)Васильева Фәридә Мирсәет кызы.* | 36 |
| 12 | **“Хыялларның канатлары янды....”** *Шәйхиева Гөлсинә Мансур кызы.* | 41 |
| 13 | **Батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм дүрт тапкыр Бөек Ватан сугышы ордены, күп медальләр белән бүләкләнгән шагыйрь Шиһабетдин Садыйков истәлегенә.** *(Ата-аналар, укытучылар һәм тәрбиячеләр өчен. Юсупова Ләйсирә Наил кызы.* | 49 |
| 14 | **Ватанны саклаучылар елына багышланган спорт күңел ачу кичәсе.** *Ягьфәрова Гөлназ Гамир кызы.* | 51 |

**АҢЛАТМА ЯЗУЫ.**

2025 ел ил башлыгы Владимир Владимирович Путин тарафыннан, Бөек Җиңүнең 80 - еллыгы, тынычлык елы һәм нацизмга каршы көрәш елы дип, ә Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миннеханов "Ватанны саклаучылар елы"дип игълан итте. Ватанны саклаучылар елы-календарь датасы гына түгел, ә милли бердәмлек һәм патриотизм символы. Бу илебезнең суверенитетын һәм иминлеген саклаган һәм яклауны дәвам иткән кешеләргә тирән рәхмәт белдерү. Бу ел безгә тарихи хәтернең мөһимлеген һәм дөньяның мәңгелек кыйммәтен искә төшерә, аны Ватанны саклаучылар үзләренең батырлыклары һәм фидакарьлекләре белән саклыйлар.
Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 80 ел узса да, сугыш хатирәләре, туган җиребезне, илебезне илбасарлардан саклап калган, аның иминлеге өчен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнарыбыз онытылырга тиеш түгел. Илебезгә шактый кыйммәткә төшкән бу җиңү шатлыгын үз күзләре белән күреп, безгә тынычлык бүләк итүчеләрнең саны да бүген авылларда инде юк диярлек. Яшисе килү теләге, тормышны, туган җирне ярату барысыннан да көчлерәк булган күрәсең. Нәкъ шушы чор кешеләре үз язмышына төшкән сынауларны сыкранмый, намусына тап төшерми үтә белгән буын. Шушы гади генә татар хатыннары, әби-бабайлар, яшүсмер егет-кызлар көнне-төнгә ялгап эшләмәсәләр, Җиңү таңын күрү насыйп булыр иде микән? Тыл батырлары, сугыш чоры балаларының кичерешләрен тыңлагач үзеннән-үзе горурлык хисе туа. Сугышның авыр җәрәхәтен иңнәрендә күтәргән хөрмәтле ветераннарыбыз бу афәтне мәңге үз хәтерләреннән җуймыйлар. Дәһшәтле еллар афәтен һәр гаилә кичергән. Күп аналар тол калган, улларын һәм кызларын югалткан. Тирән яра калдырган, йөрәкләргә әрнү салган ул сугыш.. Күңелләр һаман сызлана, сыкрый әле.

Махсус хәрби операциянең беренче көннәреннән башлап безнең ватандашларыбыз, үз вакытында Рейхстаг түбәсенә Җиңү байрагын кадаган ата-бабаларыбызның данлы батырлык үрнәкләрен дәвам иттереп, җир йөзен нацизмнан азат итә, озак көтелгән Җиңүне якынайта. Ватан өчен, киләчәк буыннарның имин тормышта яшәве өчен гомерләрен кызганмыйлар.

Без - сугыш тарихын китап белән кинодан түгел, бабаларыбыз сөйләгәннән белеп үскән ахыргы буын. Тагын берничә елдан ышанычлы чыганак булып архив документлары гына калачак. Ә тарихи хакыйкатне саклау - буыннан буынга күчәчәк амәнәт тә ул. Без үз чиратыбызда киләчәк буынны ватанпәрвәрлек хисләрендә тәрбияләргә тиешбез.

Туган (татар) телдә патриотик кыйммәтләрне кулланып тәрбия һәм белем бирү буенча методик җыентык, Удмурт Республикасы Ижау шәһәре Ленин районы “107 номерлы “Энҗе” балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары тәрбиячеләренең, башлангыч сыйныф укытучыларының тәҗрибә уртаклашу максатыннан төзелде. Тәкъдим ителгән материаллар милли балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә, әти-әниләргә, башлангыч мәктәп укытучыларына, педагогик уку йортларында белем алучы студентларга адреслана.

**“Сугышчан дан почмагы” акциясе конспекты.**

*Гиззатуллина Эльвира Дәрсил кызы*
*Әгерҗе шәһәренең 8 санлы балалар бакчасы*
*татар теле тәрбиячесе*

1 алып баручы:

Хәерле көн, балалар, тәрбиячеләр, килгән кунаклар! Бүген безнең балалар бакчасында мөһим вакыйга- Җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган геройлар истәлегенә һәм Украинадагы махсус хәрби операция геройлары хөрмәтенә “Сугышчан дан почмагы” ачу тантанасы.

2 алып баручы:




Мәңгелек ут-ялкыннардан һәйкәл-

Һәлак булганнарга сугышта.

Мәңгелек ут-алар сулышы ул,

Тоташылган безнең сулышка.

Алар исән безнең күңелләрдә,

Дәвамнары- безнең гомерләр.

Алар-миндә яши, алар- синдә яши,

Алар бездә -мәңге яшәрләр!

1 алып баручы:

Игътибар! Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы гимнары яңгырый. Дәүләт флагларына тигезләшүегезне сорыйбыз!

2 алып баручы:

Бөек Ватан сугышы геройлары, Ураинадагы махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларын үтәгәндә хәлак булган солдатлар һәм махсус хәрби операциядә катнашучы, Ватанга бүген дә тугъры хезмәт итүче солдатлар хөрмәтенә Сугышчан дан почмагы ачу тантанасын ачык дип белдерәбез.

1 алып баручы:

Бүген без солдат һәм офицерларның батырлыгы алдында баш иябез. Алар боерыкларны курыкмыйча үтәгәннәр, батырларча җиңүгә омтылганнар, үз иленә, халкына тугъры калганнар.

2 алып баручы:

Бу хәтер- исән, чөнки аны һәлак булган солдатларның иптәшләре, гаиләләре, якыннары йөрәк түрендә саклыйлар.




1 бала:

Кирәкми безгә кан кою,

Кирәкми безгә сугыш!

Безнең теләк якты, матур,

Тыныч хезмәт һәм тормыш.

2 бала:

Илебез зур, җиребез киң,

Хисапсыз байлык бездә!

Җир өстендә, җир астында,

Тауларда һәм диңгездә!

3 бала:

Без үз кулларыбыз белән

Төзибез гүзәл тормыш.

Без- тыныч ил төзүчеләр,

Кирәкми безгә сугыш! (Ә.Исхак)

1 алып баручы:

Һәм бу хәтер әле яшәячәк, чөнки без аны саклыйбыз, аның турында сөйлибез, җырлыйбыз. *(Фон итеп көй куела, балалар шигырьләр сөйли.)*

4 бала:

Басып кергән дошман Җиребезгә,

Герман иле сугыш башлаган.

Авылларны, шәһәрләрне җимереп,

Җиргә күпме бомба ташлаган.

5 бала:

Җиңү яулап кайтырга сүз биреп,

Фронтка киткән күпме әтиләр.

Авыр эштән газап чиккән толлар,

Һәр көн саен арткан ятимнәр.

6 бала:

Сугыш, сугыш! Күпме кара кайгы,

Күпме авырлыклар китергән.

Балаларның киләчәккә дигән,

Якты өметләрен яндырган.

7 бала:

Без бәхетле буын, азатлыкта

Һәм муллыкта гына яшибез.

Җиңү яулаганнар онытылмас!

Бердәмлектә бергә көчле без. (Әхмәт Рәшит)

2 алып баручы:

Сугыш... Нинди коточкыч авыр күренеш, куркыныч сүз. Сугыш ул- батырлык, югалтулар, күз яше...Җир йөзендә явызлык һәм нәфрәт булмаса гына, күңелләрдә тынычлык хөкем сөрә ала. Кирәкми безгә сугыш...

1бала:

Җиңүчеләр калака һәйкәл булып,

Һәйкәл булып баса батырлар.

Ә батырлар үлми- ике тапкыр-

Алар хәзер мәңге балкырлар!

2 бала:

Таш һәйкәлләр балкый эчтән генә,

Җырлый алар акыртын гына.

Һәйкәлләргә килик!

Гөлләр куйыйк!

Һәйкәлләрне тыңлыйк тын гына!

*(«Журавли» көе уйнаганда- балалар мемориалга чәчәкләр куя.)*

1 алып баручы:

Еллар үтәр. Сугышчан орденнар тоныкланыр. Яралар әле озак төзәлмәс.. Әмма бу сугыш халык күңелендә мәңгегә онытылмаслык фаҗигале тамга булып калыр.

2 алып баручы:

Бер минут тынлык белән,

Искә алыйк совет солдатын.

Илне саклап, яу кырында

Мәңгелеккә ятып калганын.

Бер минутлык тынлык белән,

Искә алыйк барлык солдатны.

Җиңү өчен көчен куйган,

Онытмабыз изге җаннарны. (Г.Шайдуллина)

Бүген без Бөек Ватан сугышы елларында һәм Украинадага махсус хәрби операция вакытында Ватаныбызны саклап һәлак булганнарны искә алып бер минут тынлык игълан итәбез.

*( Метроном тавышы астында бер минут тынлык)*

2 алып баручы:

Хәзерге көндә дә безнең егетләр Украинадага махсус хәрби операциядә катанашып, Ватаныбызга тугъры хезмәт итәләр. Аларның исән сау йөреп кайтуларын көтеп калабыз. Күкләребез аяз булсын, ил-көннәребез тыныч булса иде!

1 алып баручы:

Һәр туар таң җирдә тыныч булсын,

Имин булсын иде дөньялар.

Аяз күгебезне болыт капламасын,

Балкып торсын күктә йолдызлар.

"Сугышчан дан почмагы"ачуга багышланган чара ябык дип игълан ителә.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Интернет сайтлары: Инфоурок, Маам.ru, ВК челтәре.


**"Батырлар мәңге онытылмый"**

(мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән Ватанны саклаучылар елы һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан чара)


*Давлетшина Налия Нурулла кызы,*

*Шавалиева Елена Василий кызы,*

*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*

*Әгерҗе шәһәренең 1 нче санлы "Алтын ачкыч" балалар бакчасы тәрбиячеләре.*


**Чарага әзерлек:**

1. Шагыйрь китаплары күргәзмәсен оештыру

2. Герой шагыйрьнең тормышына һәм иҗатына багышланган презентация әзерләү

**Максатлар һәм бурычлар:**

1. Балаларның бөек татар шагыйре М. Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турындагы белемнәрен киңәйтергә һәм тирәнәйтергә;

2. Патриотлык, батырлык, гражданлык хисләре тәрбияләү;

3. Татар һәм рус телләрендә шигырьләрне дөрес сөйли белүне ныгыту;

4. Иҗади фикерләүне үстерергә.

**Җиһазлар:**

1. Муса Җәлил Портреты.

2. Китаплар күргәзмәсе.

3. Презентация

4. Шигырьләргә иллюстрацияләр.

*Балалар «Муса Җәлил бөек шагырь» музыкасы астында залга керәләр*

**Алып баручы:**Хәерле көн, кадерле дуслар! Бүген без яңадан шушы залга җыелдык. 15 февраль-Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең туган көне!Без бүген бөек шагырьне, ватанны саклаучы-Муса Җәлилне искә алабыз. Аның җырларын тыңларбыз, шигырьләрен укырбыз.Бүгенге бәйрәм чарасын Муса Җәлилгә багышларбыз.

*Слайд*

Ул 1906 елның 15 февралендә Оренбург даласы киңлекләрендә югалган кечкенә татар авылы Мостафада туа. Барлык крестьян балалары кебек үк, Муса да чык үләнендә яланаяк йөри, казлар көтә, инештә су коена, балык тота. Кышкы озын кичләрдә әбисе сөйләгән әкиятләрне тыңларга бик ярата . Бу иң гади малай иде, тик яшьтәшләренең күбесеннән бераз кызыксынучанрак, ярдәмчелрәк һәм кыюрак.Мусага мәктәпкәбарырга җыенганда алты яшь тә тулмаган иде әле. Олы абыйсы Ибраһим китапларны киндер сумкага тутырырга тотынса, Муса: «Мин дә укырга телим, мин дә мәктәпкә барам», - дип башлый торган була. Бер ачулана әтисе , икенчесе, каешка тотынмакчы була , ләкин әнисе сүзгә кушылды.:"Калдыр, Мостафа, - Кем белә, бәлки, улыбыз писарьлыкка өйрәнер ...» -дие.

Әтисе бик ачуы килсәдә , Мусаның кулыннан тотып, мәктәпкә китә. Габдулла Усмановны читкәрәк чакырып алды да: - тыңла әле, - диде.,-хәлфә әфәнде, малай укырга сорый, нишләргә? Укытучы кечкенә Мусага караган да , кулын селтәде: - хәзергә йөрсен. Туйдырса-үзе ташлар.

Ләкин Муса мәктәпне ташламады.

- Ул елларда барлык сыйныфлар да бер зур бүлмәдә шөгыльләнделәр. Класс дүртәү иде:алда - беренче сыйныф укучылары, икенче рәттә-икенче сыйныф укучылары, ә алда-өченче һәм дүртенче сыйныфлар. Укытучы һәр сыйныфка чиратлап биремнәр бирде-башта кече сыйныфларга, аннары өлкәннәргә.

Дәресләр башлануга якынча ай ярым-ике ай вакыт үтте, ә Муса инде укырга, язарга һәм санарга өйрәнде - бик тырыш һәм сәләтле бала булып чыкты. Укытучы Мусаны икенче рәткә күчереп утыртырга булды. Озакламый Муса аларны да узып китте һәм өченче класс укучыларына биремнәр биргәндә кулын сузды.

Укытучыга малайны өченче рәткә, аннары дүртенче рәткә күчерүдән башка чара калмады.

- Шулай итеп, Муса бер ел эчендә дүрт сыйныфның да программасын үзләштерде.

- Муса күп укыды. Ул бик җанлы, Күзәтүчән иде. Күргәннәренең барысын да кешеләргә сөйләргә теләде, ләкин гади сүзләр белән түгел, бәлки матур, җыештырылган сүзләр белән. Аңа унөч яшь тулгач, аның шигырьләре беренче мәртәбә газетада басыла.

**Алып баручы:** кем ул Муса Җәлил?

**Балалар:** татар шагыйре (Әйе, шагыйрь).

**Алып баручы:** шагыйрьләр һәм язучылар әдәби телдә сөйләшә беләләр, димәк, матур һәм дөрес сөйләшә беләләр. Без сезнең белән бакчада Муса Җәлил әйткәнчә дөрес сөйләшергә өйрәнәбез.

**Алып баручы:** Шулай ук шагыйрь вакытны сакчыл бүләргә һәм аны әрәмитмәскә өйрәтә.

*“Сәгәть» шигыре*

**Алып баручы:** Шагыйрь җәнлекләрне ярата һәм алар турында шигарьләр яза.

Әйдәгез без дә уйнап алабыз

*Уен “Эйдэгез биибез” 23 кисэк 20 тема*

**Алып баручы:** безнең илгә фашистлар һөҗүм иткәч, Җәлил фронтка китә. Бу вакытта аңа 35 яшь була. Аның өендә хатыны Әминә һәм кечкенә кызы Чулпан калды. Җәлил кызын бик ярата һәм аңа шигырьләр багышлый иде.

**Алып баручы**- Бөек Ватан сугышы вакытында Җәлил хәрәкәттәге армиядә була. Фронтта каты яраланып, әсирлеккә алына. Гитлерчылар аны Моабит төрмәсенә ябалар. Сез аның төрмәдә дә шигырьләр язганын беләсез инде. Нинди дәфтәрләр ясый иде ул? Дөрес, блокнот зурлыгында яздым, ә блокнотларны фашистлар тапмасын өчен яшердем. Бу җыентык «Моабит дәфтәрләре»дип атала. Бу шигырьләр югалмады, аларны туган иленә бик әйбәт кеше, аның дусты алып кайтты.

Ә хәзер без Сезнең белән Муса Җәлил әсәре буенча куелган «Кызыл ромашка " мультфильмын карыйбыз

*Мультфильм «Кызыл ромашкалар”*

**Алып баручы**-Ел саен Казанда шагыйрьнең туган көнендә кешеләр Җәлил һәйкәле янына җыелалар, аның шигырьләрен укыйлар, сугышсыз яшәү ничек яхшы, беркемнең дә башкаларның гомерен алырга хакы юк, дип сөйлиләр. М.Җәлилнең кызы Чулпан ел саен Казанга әтисенең һәйкәле янында була. Ул әтисенең батырлыгы белән горурлана.

**Алып баручы**-Ә М. Җәлил нинди батырлык кылган? *(Балалар җаваплары)*

**Алып баручы:** Ул үзен җәзалауларын, газаплауларын, җәзалауларын белә иде, ләкин ул барыбер дошман ягына күчмәде, фашистлар белән хезмәттәшлек итәргә ризалашмады. Шигырьләр теле белән дошманнарга каршы көрәшүен дәвам итә. Без аны–ватанчы, патриотик шагырь диеп атыйбыз.

**Алып баручы** Кем ул патриот? *(балалар җаваплары)*

**Балалар:**Туган илен, туган җирен яраткан һәм беркайчан да аңа хыянәт итмәгән кеше.

Җәлил Туган илен, кешеләрне бик ярата иде. М.Җәлилнең иҗатын һәм батырлыгын безнең илдә генә түгел, күп кенә чит илләрдә дә беләләр.Муса Җәлилнең шигырьләре безне кыю, куркусыз булырга өнди, тыныч заманда яшәү ничек шәп икәнлеге турында уйланырга мәҗбүр итә! Оренбург өлкәсенең Мостафа авылында шагыйрь хөрмәтенә йорт-

музей бар.М.Җәлил истәлеге мәңгеләштерелде. Шәһәрләрдә, авылларда М.Җәлил урамнары, аның турында китаплар, музейлар бар.

**Алып баручы**-Сез мәктәптә Муса Җәлил иҗаты белән күбрәк танышырсыз. Ә хәзер сезнең белән "Кызыл ромашка" апликация ясаячакбыз.

*Аппликация буенча коллектив эш.*

**Алып баручы:** Балалар быел Россиядә Ватанны саклаучылар елы итеп игълан ителде һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы билгеләп үтәчәкбез. Безнең илебезнең геройлары бик күп. Шуларның берсе - бөек шагыйрь Муса Җәлил турында сөйләштек без сезнең белән бүген. Безнең ата-бабаларыбыз да бөек сугышта катнашып җиңү яулаганнар.Аларның исемнәре мәңгелек.Алар аркасында без шушы матур тормышта яшиез.Һәм аларга баш иябез.Әйдәгез бер минут тынлык белән аларны искә алыйк

*(барсыда басалар, бер минут тынлык игълан ителә)*

**Алып баручы:** Рәхмәт. Без сезнең белән бүген шундый матур чара уздырдык, бөек шагыйребез МУСА Җәлил турында сөйләштек, барлык геройларны искә алдык. Илләребез тыныч булсын. Кешеләр күз яше түкмәсеннәр.

**Әдәбият исемлеге**

1. Мостафин, Р.А. Муса Җәлил: "Тормыш һәм иҗат: сугышка кадәрге чор." - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1986ел
2. Интернет -ресурслар.

**"Сугыш кайтавазы һәм йөрәк хәтере"**

*(Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган сугыш һәм хезмәт ветераннары өчен чара)*

*Газетдинова Резеда Исмәгыйль кызы,*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*Әгерҗе шәһәренең 4 нче балалар бакчасы тәрбиячесе.*

**Алып баручы.**

Хәерле көн, сугыш һәм хезмәт ветераннары! Сезнең барыгызны да бөек тантана, зур шатлык - Бөек Җиңүнең 80 еллык бәйрәме белән котлыйбыз! Илебез күгенең аяз булуы белән без сезгә бурычлы. Озын гомер, тыныч көннәр насыйп булсын барыбызга да!

*(Грамзапись тыңлау "Вставай, страна огромная")*

*(Балалар залга кереп урыннарга утыра)*

**Алып баручы**

Матурлыгы өчен бу көннәрнең
Кемнәр генә корбан булмаган!
Исемнәрен тарих безгә үзе
Саклап килә ерак еллардан!

Туган ил хакына,

Туган җир хакына

Авылдашлар башын салдылар.

Безнең гомер өчен алар

Мәңгегә чит илдә калдылар!

**Алып баручы**

Хөрмәтле кунаклар! Бу Җиңү зур корбаннар аша килде һәм менә ничә ел инде илебез халкы тыныч тормышта яши. 4 ел сугыш дәвамында халкыбыз тудырган зур батырлыклар һәм кичергән зур газаплар мәңге онытылырлык түгел.

22 июнь. Таң атып килә. Гүзәл авыллар, шәһәрләр тыныч йокыда. Әниләренең җылы куенында тәмле төшләр күреп нәни сабыйлар изрәп йоклыйлар. Шул вакытта канга туймас фашист этләре безнең чикне бозып авылларны, шәһәрләрне үлем утына тоттылар. Бөек Ватан сугышы башланды.

*(Фонограмма: Левитан тавышы. Сугыш башлануы хәбәр ителә.)*

*("Солдатлар" җыры)*

**Алып баручы**

Бер кайтмасак, бер кайтырбыз дип китсәләр дә, күпме ватандашларыбыз туган туфрагын күрү бәхетенә ирешә алмады. Алар еракта мәңгелек йокыга талдылар. Туган җирләре өчен башларын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк. Алар безнең белән, безнең арада. Безнең якты киләчәгебез, сабыйларның тыныч йокысы өчен башларын салган ватандашларны зур хөрмәт белән искә алыйк.

*(Бер минут тынлык игълан ителә)*

**Алып баручы**

Җилкәне-җилкәгә куеп төрле милләт халыклары бердәм булып явыз дошманны тар-мар иттеләр. Сугыш тынып торган арада алар шул милләт кешеләренә хас биюләр, җырлар башкарганнар.

*(Татар халык биюе)*

**1 нче бала**

Кемнәр болар, исемнәре ничек?

Белеп булмый - кайда туганнар?

Тик шунысы ачык, биеклекне

Яулаганда һәлак булганнар.

**2 нче бала**

Берсе ята гуя ял иткәндәй

Печән чапкан чакта болында.

Икенчесе ята бер уч туфрак

Кысып тоткан килеш кулында.

**3 нче бала**

Өченчесе алга карап баскан,

Кочаклаган килеш каенны.

Ул әйтә күк: фронт алга китү

Баса минем барлык кайгымны.

**4 нче бала**

Бу билгесез корбан булучылар

Безгә көрәштәшләр иделәр.

Соңгы салют биреп зурладык та,

Батыр булып гүргә иңделәр.

*(“Солдатлар” җыры )*

**Алып баручы**

Хөрмәтле әбиләр, бабайлар! Сез сугышта катнашмасагыз да, аның авырлыгын үз җилкәгездә татыдыгыз. Чөнки сез – сугыш чоры балалары. Сезнең әти-әниләрегез сугыштан соңгы җимерекләрне төзәтүдә катнаштылар. Бу күпмедер дәрәҗәдә сезгә дә кагыла. Чөнки бу чор – ачлык, ялангачлык чоры иде. Туйганчы ипи ашамау, киер кием булмау сезне куркытмады. Инде бүгенгесе көндә дә сугышлар булмасын, халыклар мул тормышта яшәсен иде. Сезгә барыгызга да исәнлек-саулык, тыныч күк йөзе телибез.

**5нче бала**

Сугышларда безне саклар өчен

Ут куйнына барып кердегез.

Кирәк чакта - һичбер кызганмыйча,

Гомерегезне хәтта бирдегез.

**6 нчы бала**

Кемне күрәм таныш татар кызы,

Күздә шатлык яше ташыды;

Ул яралы, җылы кулы белән

Күкрәгенә кысты башымны.

**Алып баручы**

Ләкин елдан ел ветераннарыбыз сафы да сирәгәя бара. Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм иткәндә арабыздан киткән ветераннарны онытмыйк. Әйе бик зур афәтләр, олы хәсрәтләр алып килде бу сугыш илебез халкына.

*(Слайд карау)*

*(Җыр “Катюша»(Зәйтүнәкәй”)*

**Алып баручы**

Хәзер сүзне сугышта катнашкан ветераннарга бирәбез.

*(Ветераннар сөйли)*

*(«Диңгезче» биюе)*

**Алып баручы.**

Яшәү өчен, авылдашларыбызның бәхетле киләчәге өчен күпме авылдашларыбызның гомере киселде. Ниһаять, зур корбаннар биреп алынган Җиңү көне килде. 1945 ел. 9 май.

*("Җиңү көне" җыры)*

**Алып баручы**

Хөрмәтле сугыш ветераннары! Сезне бәйрәмегез белән чын күңелдән котлыйбыз.

Сугыш ялкыны безнең дөньяны

Чолгап алмасын яңадан.

Сакла, сакла тынычлыкны,

Дан тынычлыкка, дан, дан, дан!

(*Балалар ветераннарга үз куллары белән ясаган открыткаларын тапшыра)*

**Кулланылган әдәбият:**

1. Балалар фольклоры һәм жырлы-сүзле йөз төрле уен/төз. Н.Исәнбәт. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1984."Салават күпере" журналы №5-2008.

2. Зарипова З.М., Исаева Р.С. Үстерешле уеннар-методик кулланма-Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.

3."Салават күпере" журналы №9-2012

4."Салават күпере" журналы №10 -2018

5. Халикова Р.Ш. Раушан көзге. Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия.-Казан "Мәгариф", 1993.

6. Шәехова Р.К. Куаныч, Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы.-Казан : Татар балалар нәшрияты, 2024.

## Икмәк сере

*(Балалар театры өчен сценарий)*

*Симакова Г.И., Латыпова А.Р.*
*МБГУ Исәнбай урта мәктәбенең*
*башлангыч класс укытучылары*

Максат:

1. Бөек Җиңүнең 80 еллыгын каршылау;
2. Укучыларда патриотик хисләр тәрбияләү;
3. Үткән, хәзерге һәм киләчәк заманнарның үзара бәйләнештә чынбарлык вакыйгаларын һәм күренешләрен аңлау сәләтен үстерү;

*Сәхнә алды. Музыка. Өлкән яшьтәге әби кыз оныгы белән кибеттән кайтып килә.. Кызчык алдан йөгерә, күкрәгенә йомры ипи кыскан.*

**Әби:** Тукта, кызым, йөгермә, чү, ипине төшереп җибәрмә! Ашыкма! Әйдә сөлгегә төреп сумкага салыйк!

*Сумкадан ап-ак сөлге алып, иплән кенә ипине төрә*

**Әби:** Икмәк - яшәү күрке бит ул, кызым. Аның валчыгын да идәнгә төшерергә ярамый.

**Кыз**: Әби, әбием! Син нигә йомры икмәкне яратасың? Гел шундый ипи сатып аласың... Әле аны күмәч тә дисең...

**Әби**: Ии кызым, ипинең карасы да минем өчен күмәчтән дә тәмлерәк аның, балам. Ә йомры ипинең кечкенәдән хәтеремә сеңеп калган хикмәте дә бар шул. Бер сөйләрмен әле мин сиңа. Ә хәзер , әйдә, балам, тизрәк кайтыйк инде, әниең дә югалткандыр. Бәлки, әтиең дә шалтыраткандыр, бер-бер хәбәре бардыр. 3 атна элемтәгә чыкмый бит бит инде. Ходаем, исән генә йөрсеннәр, балакайлар, аллахым үзе сакласын инде ул Украинадагы балаларны

**Кыз**: Ә минем әтием кайчан кайтыр микән шул Украинадан, әби? Мин аны сагындыыыым. Менә болааай кочасым килә. Әбием, берсер әйтимме? Мин әтиемә хат яздым! Сиңа гына укырмын, яме. Ә син миңа йомры икмәк серен сөйлә әле, әбием.

**Әби:** Сөйлә, дисеңме, кызым, әйдә, менә монда утырыйк та, тыңла алайса...

**Музыка**

**Госпиталь. Берничә койка. Һәрберсендә баш-куллары бинтлар белән уралган яралы солдатлар ята. Берсе култык таягы белән әкрен генә йөрергә өйрәнә, сызланудан ыңгырашулар ишетелә.**

**Шәфкать туташы (һәрбер авыру янына бара):** Хәлең ничек? Даруыңны эчтенме? Кая эле яраңны яңадан бәйлик. Күңелегезне төшермәгез, егетләр. Без сезнең белән бергәләп бу авыруларны җиңәргә тиеш!

**1 яралы.** Бүген килмиләр микәнни безнең җырчы балалар?

**2 яралы**: Килерләәәр, соңгарак калдылар бүген.

**3 яралы.** Аларны күргәч, күңелләр күтәрелеп китә шул.

*(шул вакытта сәләмә киемле балалар килеп керә)*

**1 бала.** Ә без килгәндә сезгә чәчәкләр җыйдык! (һәр солдатка чәчәк биреп чыга)

**1 яралы.** Без сезне көттек.

**2 яралы**. Бик матур чәчәкләр шул. Рәхмәт инде сезгә.

**3 яралы**. Әниләрегез сезне орышмыймы соң? Бирегә килгәнегезне беләләрме?

**2 бала.** Беләләр инде, сезгә концерт куйганны да беләләр. Аларның да киләселәре килә дә, вакытлары юк шул

**3 бала.** Алар арыйлар, урман чыгару бит ул! Авыр аларга.

**4 бала.** Кичә әнием кулын бик каты яралап кайтты. Еламады инде үзе.

**5 бала.** Абыйлар, әйдәгез мин сезгә җыр җырлыйм.

**1 яралы**. Бик яхшы булыр иде.

**2 яралы.** Син бит матур җырлыйсың.

**3 яралы.** Яле, егет, җырлап җибәр әле, күңелләр күтәрелеп китмәсме

**“Авыл көе”**

Бездә биек таулар бар ла,
Тау астында таллар бар.
Талда яфрак, бездә сагыну,
Сездә нинди хәлләр бар?

*(Солдатлар кул чабалар, мактыйлар, күз яшьләрен сөртәләр. Торалмый ята торганы үз янына чакыра.)*

**1 яралы.** Шәп җырлыйсың, егет, күчтәнәч бирим әле үзеңә (шикәр бирә)

**1 бала.** Ә минем шигырь сөйлисем килә.

*(Әйдә, әйдә, сөйлә әле, дип көч бирәләр)*

Туган илем өчен ут эчендә
Батырлыклар кыласыз...
Ватанымның көрәшләргә әзер
Сынатмас уллары сез!
Илгә- терәк. Безгә-үрнәк,
Чакматаш сез тормышта...
Өлге итеп сездәй лачыннарны
Үсеп киләбез без алмашка!

*(Менә булдырдың! Афәрин! Молодец! Кебек сүзләр яңгырый)*

**2 яралы.** Мин дә сиңа күчтәнәч бирим әле, энекәш. *(консерва бирә)*

**3 яралы.** Рәхмәт, ярый әле сез бар! Күңелләр күтәрелеп китә. Билләхи!

**2 бала.** Мин хәзер биеп күрсәтәм сезгә. *(бию башкара)*

*Малай, биеп бетергәч, кыюланып китеп, чалбар кесәсеннән өчпочмаклы хат чыгара.*

**3 бала.** Абый, сез бит дәвалангач фронтка китәм дисез. Әти дә шунда минем, менә шушы хатны әтигә бирегез әле.

**1 яралы.** (дулкынланып сәхнә алдына килә) И балакай, әтиең белән бер танкта идек бит без. Снарядка (?) эләгеп танкыбыз шартлагач, икебез ике якка очканбыз, мин менә исән калдым, ә синең әтиең....

*(Аннары малай янына килеп, җилкәсенә кулын куя)* Тапшырам, энекәш, ничек тапшырмыйсың ди мондый егетләрнең хатларын.

**2 яралы.** (балаларны сөендерергә теләп) Сезнең күчтәнәчләрегезгә каршы безнең дә күчтәнәчебез бар бит, дусларыбыз. (Бер бөтен түгәрәк ипи алып, бер кызга тоттыра.)

**Кыз:** ИПИ! (Иснәп карый) ИПИ! Әбием пешергән күмәч исе килә!

**3 яралы:** Баракка кайткач, әниләрегез белән бергәләп ашарсыз!

Шәфкать туташы: (керә) Балалар, абыйларыгыз арды, аларга ял кирәк, ә сез иртәгә килерсез. Хәзер барыгыз инде, кайтыгыз.

*(Рәхмәт, сау булыгыз, тагын килегез, көтәбез, терелегез, дигән сүзләр яңгырый)*

*МУЗЫКА*

*Әби белән кыз сәхнә алдында*

**Әби:** Менә кызым,минем түгәрәк кара икмәккә олуг хөрмәтем әнә шул еллардан килә. Безнең буын туя икмәк курми интегеп үскән буын шул, кызым. Язгы ташуларда кар сулары ерып капчык-капчык симәнә орлыклары ташыганда да, аллага шөкер, бүген дә исән-имин кайтып җиттек дип, сөенә торган идек. Икмәк- безнең өчен иң кадерле, буй җитмәс ризык булды. Ачлыктан тилмергән бала чагымда әнә шул яралы солдатлар биргән түгәрәк кара ипи- минем өчен дөньядагы иң тәмле, иң кадерле ризык булды. Баракка кайткач, әниләребез икмәкне бик кадерләп барыбызга да бүлделәр, валчыгын да әрәм итмичә ашадык без аны.

**Кыз:** Әби, кара әле, безнең йортыбызга таба ниндидер солдат абый килә. Әби, әтием бит бу, әтиеееем! *(Бала әтисенә таба йөгерә)*

**Әби:** Я Аллам, бу көннәрне дә күрерләрем бар икән! Улым, бәбекәем минем!

*Диләрәнең әтисе кайткан, хәрби операциядән кайткан, дип шаулашып балалар керә, солдат аларның барысын да кочаклый.*

***(“Тынычлык җыры” Г.Зарипова сүзләре)***

## Онытылмас еллар

*(Балалар театры өчен сценарий)*

*Симакова Г.И., Латыпова А.Р.*
*МБГУ Исәнбай урта мәктәбенең*
*башлангыч класс укытучылары*

**Өй күренеше. Кич. Әби тәрәзә пәрдәләрен тартып куя. Йокларга әзерләнәләр. Аннан оныгы янына килә.**

**Бала белән әби сөйләшә.**

**Бала.** Әби, әбием. Мин бүген телевизордан кино карадым. Сугыш турында иде ул. Үзе мавыктыргыч та, үзе шундый куркыныч.

**Әби**. Мин сиңа ничә тапкыр әйттем инде,улым, йокларга ятар алдыннан куркыныч кинолар карама, аннан төш күрәсең, елап уянасың. Әйдә, ят, мин сиңа әкият укыйм....(**әби әкият китабы ала да “Борын – борын заманда....” дип укый башлый, укыган кебек итә, бала йоклап китә. Әби бишек җыры да көйләп ала. Аннары баланың өстенә әйбәтләп яба да, өстәл янына барып утыра, уйлана.)**

**Әби.** (оныгына карап ала) Әй балакаем, сугыш турында кино карадым, ди, курыктым, ди. Куркыныч шууул, ул еллар искә төшсәәәә...иии, без яшь чакларда... **(әби хәтеренә төшерә)**

**Музыка «Вставай страна огромная»**

**Әби.** Илебездә Бөек Ватан сугышы башланды. Сугыш җилләре беркемне дә аямады шул...

**1 бала:** Дәрескә йөри алмаучылар күбәйде. Без укырга килмәүчеләрне җыярга барабыз. Хәкимова Галимәне чакырырга килдем. Әнисе иске итек күтәреп чыкты. Итекнең ямар җире дә калмаган. “Кызым, 3 кешегә менә шушы итек бар. Мин кисәм, балаларга юк, алар кисә, миңа юк,” -дип, елап җибәрде. Ул бала, шулай итеп, укуны бетерә алмады

**2 бала:** укыту бик авыр шартларда бара. Кием-салымнар начар, балаларның ашарларына юк. Укырга китаплар, дәфтәрләр җитешми. Класста 43 укучыга нибары бер “Әлифба, язарга да үзебез сызып ясаган дәфтәр.

**3 укучы:** Мәктәп иске, салкын, ягарга җитәрлек түгел. Кыш вакытында, көннәр кыска булу сәбәпле, караңгыга калып укытырга туры килә. Җиделе, унлы лампадан төшкән яктылык бик начар иде”

**Әби.** Укырдай балалар укый алмады. Ашарга, кияргә булмады, яшьтән авыр хезмәттә изелде шул безнең буын балалары. Үзенә күрә яшь чак күңелле дә иде инде.

**Уракчы кыз биюе.**

**1 кыз**. И кызлар! Бүген көн кыздырачак.

**2 кыз**. Каян беләсең? Әле кояш та чыкмаган бит!

**1 кыз**.Беләм, бүген ничектер көн кызу булырга охшаган. Күңелем шулай сизә.

**3 кыз.** Сиңа гел шул инде. Бүген кояш кыздырганчы эшләп калыйк дигән фикер дә синеке бит. Бригадирын да әйтер идем. Хы, көн кызу булыр , имеш. Йокы килә монда.

**4 кыз.** Ярар, ярар. Җитте, кызлар. Кызлар - кымызлар һавадагы йолдызлар диләрме әле. Чү, әнә өченче бригада кызлары да әче таңнан чыккан бит. Киттек, йөгердек кызлар. **(уракчы кыз биюе)**

**Әби.** Хатын-кызлар, балалар җилкәсендә булды инде бөтен авыр эш. Эшенә генә түзәр идең дә бит, йөрәкне өзеп, сугыштан авыр хәбәрләр килә шул, хат-хәбәрләр көтеп көннәр, төннәр уза...

**(Хатын-кызлар оекбаш бәйләп утыра. Фатыйма бер тәрәзәдән- бер тәрәзәгә карап йөренә.)**

Х-ә: Мәргүбә малаеңнан бер дә хәбәр алганыгыз юкмыни соң?

Ана: Юлдан гына бер хат язган иде, шуннан соң бер хәбәр дә булмады. Әнә киленебез дә җанын кая куярга белми, бик кайгыра.

Х-ә: Сугыш бит инде ул Мәргүбәкәем, шулайда бер хәбәр булмый калмас әле.

Ана: Белмим инде... Әнә, гел күңелсез хәбәрләр генә ишетелә. Яраланган килеш дошман кулында калган солдатлар да бик күп дип сөйлиләр.

Ф-а: Ул кадәр үк өметсезләнмик әле әнкәй.

Ана: Үлгәндер инде үлгәндер. Якыннарының күңеленә авыр булмасын дип юри әйтми торганнардыр әле. Менә бу оекбашны да барлык җан җылымны салып улыма дип бәйләдем.

Х-ә: Әйе, без һәрберебез, авылдагы барлык ялгыз калган аналар,улларыбызга һәм фронттагы ирләребезгә оекбаш-бияләйләр бәйләдек. Шушы җан-җылыбызны биреп бәйләгән әйберләр аларга көч-куәт биреп торсын иде.

**(Тыштан ишетелә - Фатыйма апа сезгә Ярулла абыйдан хат бар, иң беренче сезгә килдем )**

Ф-а: Әй рәхмәт яугыры. Әнкәй Ярулладан хат ба

М-ә: Укы кызым, тизрәк укы,ниләр язды микән?

(Фатыйма хат укый, солдат тавышы белән хат укыла)

«Сагынычлы хат башы, языгыз, әнкәй, каршы. Исәнмесез, җандай кадерле булган әти, әни, Фатыймам. сеңелләрем! Сезнең тарафларга газиз углыгыз Ярулладан бик сагынып һәм саргаеп, ялкынлы сәламнәремне багышлап каламын. Шулай ук барча авылдашларга күктәге йолдызлар санынча кайнар сәлам. Хатны ешрак салыгыз. Минем өчен тыныч булыгыз. Хатыгыз буенча сезнең дә соңгы көннәрдәге тормышыгыз белән таныш булдым, бик шатландым .Минем өчен артык көймәгез, әти-әни, әлегә исән-сау, тамак тук, Яхшы, хуш, сау булыгыз. Тиз көннәрдә Гитлер явын туган ил җиреннән мәңгегә каулап чыгарып, шатлык белән туган илдә бергә-бергә яшәүләрне теләп улыгыз Ярулла. 13.3.44 г.».

**Ана**. “Бияләйләр, оекбашлар бәйлим
Балам сиңа озын кичләрдә.
Бик сагындык сине, тиз кайт инде,
Я юатчы кереп төшләргә”.

**Әби.** Иии, уйланып утырып, таң атканын да сизми калганмын. Түбән өч малайлары уйнарга да чыкканнар инде, Улым, син тордыңмы соң, иптәшләрең уйнарга чыкканнар бит. (малай күзләрен уып чыгып. Тәрәзәдән карый)

**Малай.** Охо, Тррррлы уйныйлар. Әби киттем мин. (чыгып чаба)

**Әби.** (тәрәзәдән карый) Сугышлы уйнап йөргән булалар. Бәбекәйләрем, уенда гына калсын инде, күрергә язмасын сугыш афәтләрен. (кереп китә)

**Малайлар трррлы уйный-уйный сәхнәгә чыгалар. (әзрәк уйнаганнан соң )**

**1 солдат:** Ватан сугышында җиңү яулап,
Кайтты безнең ерак бабайлар.
Патриотлар булып үсәрсез.-дип,
Ышанабыз сезгә,малайлар.

**2 солдат:** Бабайлар юк,исемнәре яши
Тарих битләрендә,күңелдә.
Олы хөрмәт белән без аларны
Искә алабыз менә,бүген дә.

**Г.Гәрәева сүзләре һәм музыкасы "Кечкенә солдатлар" җыры (җыр сәхнәләштерелә)**

Яшел гимнастёрка,
Йолдызлы пилотка.
Безнең өсләрдә,
Безнең өсләрдә.
Погоннар иңнәрдә,
Каешлар билләрдә.
Безгә килешә.
Безгә килешә.

Куш. Бер, ике өч безгә карагыз,
Бер ике өч, җырлап барабыз.
Бер, ике, өч, без бит солдатлар,
Бер. Ике. Өч. Нык безнең сафлар.

Сокланып карыйлар,
Әбиләр, бабайлар,
Елмаеп калалар
Апалар, абыйлар.
Сәлам, сәлам кызлар,
Якты безнең юллар,
Хыяллар-теләкләр
Матур безнең уйлар.

Куш.

Хәзергә уйныйбыз,

Солдат уеннарын.

Танклар йортәбез,

Диңгез корабларын.

Килеп җитәр ул көн,

Без үсеп җитәрбез,

Ватанны сакларга,

Солдатка китәрбез.

Куш:

**1 кыз:** 1,2,3 үсеп җитәрсез.

Туган илгә сез

Хезмәт итәрсез. **(кулындагы яулыгын солдатка бирә)**

**Бабай:** Сез әлегә сабый,солдат булып,

Уйнап үсә торган яшь буын.

Танклар да, диңгез корабы да

Сезнең өчен бүген тик уен.

**2 кыз:** 1,2,3 атларсыз алга.

Атларсыз алга

Тигез сафларда. **(кулындагы яулыгын солдатка бирә)**

**Әби:** Кайсы гына малай теләми соң,

Автоматын тотып кулына.

Кайсы гына малай хыялланмый

Батыр солдат булу турында.

**3 кыз:** 1,2,3 сезнең саф корыч.

Илне сакларсыз,

Ил булыр тыныч. **(кулындагы яулыгын солдатка бирә)**

**Әти:** Ышанабыз сезгә,әй,яшь буын,

Киләчәк бит сезнең кулларда.

Дошман явы үтеп керә алмас,

**Р.Миңнуллин "Дәшәбез сезгә, өлкәннәр"**

**"Яшәсен тынычлык!" җыр**

**“Кем безгә Бөек Җиңү яулаткан?”**

(*Бөек Җиңү турында балаларның сөйләм телен үстерү буенча педагоглар өчен семинар-практикум)*

*Кавиева Лилия Фаатовна,*
*укытучы-логопед,*
*Әгерҗе шәһәренең “Атын ачкыч”исемле*
*1 нче санлы балалар бакчасы*

**Семинарның максаты:**

1. Балаларның сөйләм теле үсешен ярдәм итү: Педагогларга балаларның сөйләм телен һәм коммуникатив күнекмәләрен үстерү өчен актуаль методик алымнар белән таныштыру.

2. Бөек Җиңү темасының әһәмиятен аңлату: Балаларга Бөек Җиңү турында дөрес, тарихи һәм мәгънәле мәгълүмат бирү, аның алар өчен әһәмиятен аңлауга күчерү.

3. Интерактив методлар куллану: Педагогларны актив уку процессын оештыру өчен интерактив методлар һәм уен элементларын кулланырга өйрәтү.

4. Иҗади эшчәнлекне стимуллаштыру: Балаларның иҗади потенциалын ачу һәм иҗади эшчәнлеккә аерым игътибар бирү, аларны кызыксындыру.

5. Карашны киңәйтү: Педагоглар арасында тәҗрибә уртаклашу, методик ресурслар белән танышу һәм яңадан-яңа идеяләр җиткерү.

6. Балаларның тарихи аңын үстерү: Бөек Җиңү темасы аша балаларда патриотик хисләр формалаштыру, тарихка һәм аны хөрмәт итүгә игътибарны арттыру.

Әлеге максатларны тормышка ашыру семинарның төп өстенлеге булып тора, һәм ул педагогларның партиципатив методологияләрне куллануны камилләштерүгә ярдәм итә.

**Ресурслар:**

Күрсәтмәләр, презентацияләр, методик ярдәмлекләр, китаплар, видеоматериаллар.

**Кереш өлеш:**

Бөек Җиңүнең тарихи әһәмияте турында кыскача лекция.

Бөек Җиңү - безнең тарихыбызда иң мөһим вакыйгаларның берсе. Ул 1945 елның 9 мае көнне гомуми фашистик Германиягә каршы сугышта мөһим җиңү итеп тарихка керде. Бу җиңүне безгә яулаткан кешеләр – ул безнең батыр бабайларыбыз, сугышта катнашкан солдатлар һәм офицерлар, шулай ук мир өчен көрәшкән хатын-кызлар, балалар һәм картлар.

Кемнәр безнең өчен Бөек Җиңү яулаткан?

1. Солдатлар: Алдынгы сафларда сугышка чыккан, батырлык белән дошманга каршы торган ир-атлар. Аларның күпчелеге үзләренең яшен, гаиләләрен, киләчәген ташлап фронтка киттеләр.

2. Ветераннар: Сугыштан кайтканнар, хәтта яраланып, туган якларына кайтканнар. Алар безгә безнең тарихны, батырлыкларны һәм корбаннарны сөйлиләр.

3. Хатын-кызлар: Сугыш вакытында эти-әниләрен, ирләрен югалткан, әмма ике һәм өч бала тәрбияләгән хатын-кызлар. Алар фронтта да эшләгәннәр, госпитальләрдә дә, заводларда да.

4. Балалар: Сугыш вакытының авырлыкларын кичергән, тавышсыз, әмма зур батырлык һәм сабырлык белән үскән балалар. Алар да фронтка ярдәм итәр өчен кулларыннан килгәнчә тырышканнар.

5. Бөтен халык: Сугыш вакытында бердәм булып, ил өчен көрәшкән, икътисадны һәм көнкүрешне саклаган халык.

Ни өчен без моны онытмаска тиеш?

Бүгенге көндә без Бөек Җиңүне бәйрәм итү белән генә чикләнмибез, ә безнең киләчәк буыннар өчен шуны аңлатырга тиешбез. Безнең бурыч - бабаларыбызның батырлыгын, корбаннарын исендә тоту һәм мир, тынычлык өчен көрәшләрен онытмау.

Безнең йөрәктә Бөек Җиңүнең истәлеген саклап, без аны киләчәк буыннарга да тапшырырга тиеш. Тынычлык һәм тыныч тормыш өчен көрәшү һәр кешенең бурычы!

**Мәгълүмати блок:**

Балаларда сөйләм телен үстерүнең методлары һәм алымнары.

1. Бөек Җиңү тарихы:

   - Бөек Җиңүнең әһәмияте, аның тарихы һәм төрле вакыйгалар.
   - Балаларга Бөек Җиңү турында мәгълүмат җиткерүнең формалары.

*Презентация тәкдим итү*

2. Сөйләм теле үстерү методлары:

   - Балаларның сөйләм телен активлаштыру өчен уеннар һәм интерактив методлар.
   - Тарихи темаларга кагылышлы диалоглар һәм бәхәс формалаштыру.

*Педагоглар өчен сайтлар, автор кулланмалар, дидактик уеннар белән таныштыру*

Уеннар, диалоглар һәм иҗади проектлар балаларның белемнәрен, иҗади фикерләвен, танып белү күнекмәләрен үстерү өчен файдалы була ала һәм осталыкларын актив рәвештә камилләштерергә ярдәм итә.

Уеннар:

1."Сорау-җавап уены"

 - Балалар төркемнәргә бүленеп, сорауларга җавап бирә, һәм һәр дөрес җавап өчен очкалар ала. Соравлар тарих, мәдәният һәм Бөек Җиңү темасына бәйле булырга мөмкин.

 - Уенчы үзенә бирелгән карточкалардан сорау укучы, ә калганнар дөрес җавап табарга тырыша. Бу уен интерактив һәм балаларның коммуникациясен үстерә.

2. "Сыйфатлар уены"

 - Балалар карталар буенча бер-берсенә сыйфатлар кулланып, үз героик образларын тудыра. Мәсәлән, "Бөек Җиңүдә потратил герой" кебек тамгалар куллана.

Диалоглар:

1. "Тарихи персонажлар очрашуы"

- Балалар тарихтагы билгеле персонажлар роленә керәләр һәм бер-берсе белән диалог корып, үзләренең кебек уйлаган нәрсәләр турында сөйләшәләр.

2. "Әби белән бабайның тарихы"

- Балаларның өлкәннәрдән һәм ата-аналардан тарихи вакыйгалар турында сорашуы. Ул контекстта диалог корырга теләсәләр, үзләренең сорауларын куя алалар.

3. Творчество һәм иҗади эшчәнлек:

- Бөек Җиңү темасына бәйле рәсемнәр, шигырьләр, хикәяләр язарга булдырырга.

- Балалар белән берлектә проектлар эшләү.

*Педагоглар өчен сайтлар, автор кулланмалар тэкдим итү*

Иҗади проектлар:

1. "Тарихи плакат"

- Балалар төркем булып Бөек Җиңүгә багышланган плакат яки коллаж ясый. Аларның һәрберсе уникаль стильдә сөйли һәм тарихи элементларны күрсәтеп, төсле һәм иҗади итеп эшләтә.

2. "Тарихи хикәя язу"

- Балаларга Бөек Җиңү темасына бәйле хикәя язарга тәкъдим итеlә. Аларның үз фикерләрен, хисләрен һәм күзәтүләрен кулланып, иҗади күзлектә иҗат итә алалар.

3. "Тарихи видео"

- Балалар видеофильм төшереп, Бөек Җиңү тарихын ысуллар белән сатып алу. Бу проектта алар сценарий язар, роликлар уйнап, видеосъемка үткәрәләр.

4. Эш кимәлләре буенча методик тәкъдимнәр:

- Яшендә балалар өчен теманы аңлаешлы һәм кызыклы итеп тәкъдим итү.

**Практик өлеш:**

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен Бөек Җиңү темасында сорау-җавап уены өчен гади һәм аңлаешлы сораулар тәкъдим итәм:

Бөек Җиңү

1. Сорау: Бөек Җиңү кайсы көнне билгеләнә?

- Җавап: 9 майда.

2. Сорау: Бөек Җиңү - бу нидән гыйбарәт?

- Җавап: Бу сугышта дошманнарны җиңү.

3. Сорау: Безнең илнең символы нинди?

- Җавап: Туган илебезне ярату һәм аның өчен көрәшү.

Геройлар

1. Сорау: Сугышта геройлар кемнәр?

- Җавап: Хатын-кызлар, балалар һәм ир-егетләр, алар илне саклады.

2. Сорау: Геройлар нинди эшләр эшләделәр?

- Җавап: Алар фронтка киттеләр һәм илебезне сакладылар.

Вакыйгалар

1. Сорау: Сугыш турында нинди китаплар укырга мөмкин?

- Җавап: Батырлык турында китаплар, бигрәк тә балалар өчен язылганнар.

2. Сорау: Бөек Җиңүгә кояш, чәчәкләр белән нигә бәйлиләр?

- Җавап Чөнки без батырларның хәтеренә дан куйганга күрә.

3. Сорау: Сугыш вакытында балалар ничек ярдәм иттеләр?

- Җавап: Алар фронтка ярдәм итеп, немецларга каршы чыктылар.

Символлар

1. Сорау: "Мәңгелек ут" нәрсә ул?

- Җавап: Геройларның рухын искә алу өчен янып торучы ут.

2. Сорау:Бөек Җиңү әһәмияте нидә?

- Җавап: Безнең илнең бәйсезлеге һәм тынычлыгы.

Бу сораулар һәм җаваплар балаларның Бөек Җиңү тарихын аңларга ярдәм итәчәк, һәм алар белән кызыклы уен оештырырга мөмкин. Уйнау процессында алар тарихи белемнәрен баетырга һәм патриотизмны көчәйтергә ярдәм итәчәк

**Нәтиҗә ясау:**

Педагоглар үз тәҗрибәләре белән уртаклашу, нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр.

Мондый семинар балаларның сөйләм телен үстерү буенча мөрәҗәгатьләрен көчәйтергә, Бөек Җиңү темасын тәмамлау өчен кызыклы һәм мәгълүматлы форматта үткәрү өчен ярдәм итәчәк.

**Файдаланылган әдәбият**

Интернет чыганаклары: Бөек Ватан сугышы темасы буенча мәгълүмат.

Электрон ресурслар: педагоглар өчен сайтлар “Воспитателям и специалистам ДОУ», «Воспитатель-педагог», «Лэпбуки и поделки».

## “Күңелләрдә мәңге сакланыр”

***(Мәктәпкә әзерлек төркем балалары өчен)***

*Рамазанова Гөлчәчәк Мөсәвир кызы.*

*Беренче категорияле тәрбияче*

*Кадыбаш урта гомумбелем бирү мәктәбе*

**Бурычлар:**

1. Балаларга патриотик хисләр ,туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.

2.Сугыш чоры вакыйгаларын балаларга аңлаешлы итеп җиткерү.

3.Өлкән буын кешеләренә игътирамлык тәрбияләү.

**Сүзлек:** Бөек Ватан сугышы, Җиңү көне , парад, ветеран, батыр, патриот.

**Җиһазлар**:Авылыбыз ветераннары белән эшләнгән призентация, "Хәтер"китабы. "Җиңү көне"(А.Гайнетдинова сүзләре һәм көе) җыры.

1. **Көнне каршылау мизгеле**.

Балалар, мин сезне күрүемә бик шатмын.Бүген сез шундый шатмын ,көр күңелле ,һәркем дустына елмая .Мин сезне шатлык түгәрәгенә чакырам .Әйдәгез ,кулга-кул тотыштык та бер-беребезне матур сүзләр белән сәләмлик:

Дөняда яшәү рәхәт!

Дус булуы күңелле!

Дусларың булу бик шәп!

Минем булу да бәхет!

**2 Төп өлеш:**

**Тәрбияче.**Сугыш килде безгә сорамыйча,

Шакымыйча керде ишекне,

Кабатладык шулчак тешне кысып;

"Без җиңәргә тиеш ничектә"

1941 елның 22 июнендә немец – фашист илбасарлары безнең илебезнегә басып керделәр,шәһәрне,авылларны талый ,яндыра башладылар.Халкыбыз,бердәм булып ,дошманга каршы көрәшкә күтәрелә.

**Җыр тыңлау**: "Җиңү көне"(А.Гайнетдинова сүзләре һәм көе)

**Үстерешле диалог.**

**Тәрбияче.**Сугышта һәләк булганнарны ничек атылар?

**Балалар.**Геройлар,батырлар.

**Тәрбияче.**Бөек Ватан сугышында Җиңү яулап кайткан сугышчыларны хәзер ничек дип йөртәләр?

**Балалар**.Ветераннар.

**Презентация карау** :Авылыбыз ветераннары белән презентация карау. Аларның исемнәре, батырлыклары белән танышу.Орден медальләрен карау.

**Тәрбияче** . Безнең Бөек Ватан сугышында һәләк булган геройларның исеме кайсы китапка язылган.

**Балалар.**"Хәтер " китабы.

***"Хәтер"китабы белән танышу. Авылыбыздан киткән батыр салдатларны барлау.***

***Тәрбияче.Хәтер китабы илебезнең горурлыгы дип атала.***

**Физ.минутка. «Самолетлар»**

**Тәрбияче.**Әйдәгез ял итеп алыйк.Күнегүләрне минем арттан кабатлагыз.Самолетлар гөрселдиләр (куллар күкрәк турында,терсәктән бөгелгән);самолетлар очалар(кулларны сузабыз,чиратлашып бер яктан икенче якка авышабыз);тыныч кына болынга утыралар(чүгәләргә,куллар тезләрдә);һәм тагын очтылар (2-3 тапкыр кабатларга)

**Э.Шәрифуллина "Минем бабай"**

Минем бабам –капитан,
Сугышта булып кайткан.
Күкрәк тулы орденнар,
Медальләр алып кайткан.
Безнең илдә һәр бала
Уйнап-көлеп йөрсен дип,
Хәвеф –хәтер күрмәсен,
Тыныч булып үссен дип,
Бик күп сугышкан бабам,
Дошманны җиңеп кайткан.
Үзе белән ул безгә
Тынычлык алып кайткан.

**3.Йомгаклау**.

"Җиңү көне"дигән темага кумәк рәсем ясау

Тәрбияче. Балалар ,без бүген белем бирү эшчәнлеге барышында нәрсәләр эшләдек?

Балалар.Авылыбызның ветераннары белән таныштык, "Җиңү бәйрәме"шигырен укыдык,рәсемнәр ясадык.

Тәрбияче.Белем бирү эшчәнлеге барышында сез бик актив булдыгыз.Әйдәгез ,хәзер ясаган рәсемне карыйк.Нинди матур рәсем килеп чыккан!Мин рәсемне тырышып ясавыгыз өчен шатланам.

**Интегральләштерү**.Балалар белән 9 май көнне "Бесмертный полк"парадында катнашу . "Җиңү көне"нә багышланган шигырьләр сөйләү.Бөек Ватан сугышы ветераннарына чәчәкләр бирү.Һәйкәлгә чәчәкләр кую.

**Кулланылган әдәбият исемлеге**

1.Туган телдә сөләшәбез : тәрбиячеләр өчен методик кулланма/Төз,;З.М ЗЧаллы,2021.-128б

2.Хәтер китабы

3."Балачак аланы": тәрбиячеләр һәм эти-әниләр өчен хрестаматия.Төз/К.В.Закирова, Казан, 2011-525б

**«Онытылмады, онытылмас!»**

(*Мәктәпкә әзерлек төркемендә*
*Бөек Җиңүнең 80 еллыгы уңаенан шөгыль конспекты)*

*Гыйльманова Айсинә Рәфис кызы*
*Тирсә авылы “Миләушә” балалар бакчасы*
*муниципаль бюджет мәктәпкәчә*
*белем бирү учреждениесе, тәрбиячесе*

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларда патриотик хисләр тәрбияләү өчен шартлар булдыру.

**Бурычлар:**

**белем бирү:**

- Бөек Ватан сугышы барышында кешеләрнең батырлыгы турында күзаллаулар формалаштыру;
- әдәби, музыкаль әсәрләрне кабул итә белүне үстерү, тәрбияче сөйләме барышында куелган сорауга тулы җавап бирә белүне ныгыту;

**үстерү:**

- сүзлек запасын Ватан, якларга, горурланырга, көрәшергә, халык, каһарман сугышчылар, очучылар, фашизм, генераллар төшенчәләрен ачыклау хисабына баету;

**тәрбия:**

- патриотизм, үз Ватаныңа мәхәббәт хисен балаларга аңлаешлы булган һәм аларда көчле хис-кичерешләр уятырлык горурлык, Бөек Ватан сугышы ветераннарына хөрмәт хисе, аларны кайгырту теләге нигезендә тәрбияләү.

**Төп белем бирү өлкәсе:** сөйләм үсеше.

**Интеграцияле белем бирү өлкәсе:** социаль-коммуникатив үсеш, сәнгать үсеше.

**Методик алымнар:** әңгәмә, нәфис сүз, күрсәтмәлелек, мөстәкыйль эш.

**Җиһазлар һәм материаллар**: интерактив такта, ноутбук, кинолента «Сугыш битләре» презентация, сугыш турында иллюстрацияләр, сугыш турында җырлар.

**Сүзлек эше:** каһарман, үлемсез.

**Алдан эшләнгән эш:** Бөек Ватан сугышы турында презентация, альбомнар карау, шигырьләр өйрәнү, Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм тылда эшләгән дәү бабайлар һәм дәү әбиләрнең фотоларыннан «Үлемсез полк» әзерләү.

**Структура.**

**I. Кереш өлеш.**

Оештыру. «Һәрвакыт булсын кояш» җырын тыңлау.

Кинолента карау «Сугыш битләре»

**II. Төп өлеш.**

Әңгәмә. «Нәрсә ул сугыш?»

Нәфис сүз.

Левитан сөйләмен тыңлау.

Ял минуты «Батырлар»

Виртуаль сәяхәт «Онытылмады, онытылмас!»

Балаларның мөстәкыйль эше. «Үлемсез полк»

**III. Йомгаклау өлеше.**

- Рефлексия.

- Иҗади эш.

**Эшчәнлек барышы.**

**I. Кереш өлеш.**

**Оештыру.** («Һәрвакыт булсын кояш» җыры яңгырый.) Тәрбияче балалар белән җырның нәрсә турында булуы, ни өчен малайның мондый сүзләр язуы турында фикер алышу: «Һәрвакыт булсын кояш, һәрвакыт булсын һава, һәрвакыт булсын әни, һәрвакыт булыйм мин».)

**Тәрбияче.** Дөрес, кешелек тарихында балалар интеккән, әниләрен югалткан, баш очында тынычлык булмаган чор булган... Нинди замана соң бу? Әйдәгез, бу чор турында кинолентага күз салыйк.

**Кинолента карау «Сугыш битләре»**

(Балалар, тәрбияче белән бергәләп, Бөек Ватан сугышы турындагы кинолента карыйлар). Тәрбияче безнең Ватаныбыз тарихында сугыш булуын аңлата. Балалардан бу турыда нәрсә белүләрен сорый.)

**II. Төп өлеш.**

**Тәрбияче.** Дөрес! Бу Бөек Ватан сугышы дүрт елга сузылды һәм халкыбызның җиңүе белән тәмамланды. Әйдәгез, тагын бер тапкыр искә төшерик, бу нинди җиңү, безнең бабаларыбыз кемне җиңгән?(*җаваплар)*

**Тәрбияче**. Әйе, бу бик куркыныч сугыш булган. Фашистлар һәм аларның баш юлбашчысы Гитлер үз армиясен җыеп, аны танклар, самолётлар, пулемётлар белән коралландырган һәм безнең илгә һөҗүм иткән. Алар безнең илдәге халыкны юкка чыгарырга теләгәннәр. Ләкин аларның бу эше барып чыкмаган. Бөтен халык илне яклап чыга һәм Бөек Ватан сугышы башланып китә. Көн артыннан көн, ай, ел артыннан ел буе безнең халык фашистлар армиясе белән көрәшкән һәм җиңү яулаган. Чөнки гаделлек өчен көрәшүче кеше үз илен, үз халкын яклый, һәрвакыт җиңә. Бу турыда безгә балалар сөйләрләр.

Батыр һөнәр бар җирдә –

Җирне, илне саклаучы.

Сине, мине – һәркемне

Дошманнардан яклаучы.

Генералмы, майормы,

Капитанмы, я сержант –

Барысының да исеме

Дөньяда бер – ул солдат.

Ватанны саклаучылар

Аямыйлар үз-үзен.

Беләкле, йөрәклеләр,

Һәм алар бар да түзем.

**Тәрбияче**. Булдырдыгыз! Ә хәзер мин сезгә сугышның ничек башлануын сөйлим. («Священная война» җыры яңгырый. Беренче куплетны тыңлагач, тәрбияче җырны ишетелер-ишетелмәс кенә куя һәм сөйли.) 1941 елның 22 июнендә шәһәрләр һәм авыл урамнарында бик күп кеше җыелган, чөнки барлык почмаклардан сугыш башлану турында хәбәр килгән. (Левитан сөйләме яңгырый) Шул көннән башлап барлык кешеләр үз Ватанын яклауга күтәрелгән. Сугыш вакытында күп батырлыклар кылынган, күп кенә сугышчылар һәм гади кешеләр сугыш каһарманына әверелгән. Сез ничек уйлыйсыз, «Батырлык» нәрсә ул? Ә батырлык эшләгән кеше ничек атала? Батыр нинди булырга тиеш*? (җаваплар*) Дөрес! Ә көчле булу өчен физкультура белән дус булырга кирәк.

**Ял минуты «Батырлар»**

Без очучы, пилотлар *Самолет очкан хәрәкәт*

Йөртәбез самолётлар.

Танкистлар, ракетчиклар *ике якка бөгелү*

Яшерен разведчиклар. *ирენгә бармак тидереп Т-ссс дип күрсәтү*

Без диңгезче, (*йөзү хәрәкәте*)

солдатлар (*маршировка)*

Барыбыз шәп – батырлар! *(баш бармакны Шәп дип күрсәтү)*

Әлегә үсеп җитик, (*аяк очларына басу)*

Уенны дәвам итик!

**Тәрбияче.** Бөек Ватан сугышына Әгерҗе районыннан фронтка 14 042 кеше киткән. Аларның 1 573 е - һәлак булган, 4 947 - хәбәрсез югалды, 4 522 - тере килеш кайткан. 2024 елның 11 декабренә Әгерҗе районында Бөек Ватан сугышында катнашкан бер кеше – Сәүбән Миңнехуҗин исән калган. Һәрбер авылда диярлек сугышта катнашучыларның исемен мәңгеләштерү өчен мемориаль комплекслар бар. Алар турында виртуаль сәяхәттән белергә мөмкин.

**Виртуаль сәяхәт «Онытылмады, онытылмас!»**

**Тәрбияче.** Безнең каһарманнар сугышта җиңү яулап күп дәүләтләрне рәхимсез дошманнан азат иткән. Быел Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 80 ел булачак, ә 2012 елда

беренче тапкыр Бөек Ватан сугышы геройлары истәлеген сакларга тиешле «Үлемсез полк» акциясе оештырылды. Һәркем үз гаиләсендәге батырның фотосурәте белән 9 нчы майда Бөек Җиңүгә багышланган чараларда катнашу өчен чыгарга мөмкин. Без үзебезнең батырларның исемен мәңгеләштерү өчен эти-әниләрегез белән бергәләп дәү бабайлар һәм дәү әбиләрнең фотоларыннан «Үлемсез полк» әзерләдек. (берничә баланың чыгышы)

**Тәрбияче.** Безнең тыныч тормышыбыз өчен көрәшкән батырларны искә алып бер минутлык тынлык игълан итәм. Быел 80 нче тапкыр Җиңү көнен бәйрәм итәчәкбез. Бу бәйрәм шатлыклы һәм фаҗигале булып кала бирә. Бөек Җиңү өчен горурлану хисе, халкыбыз түләгән коточкыч бәя турындагы истәлекләр беркайчан да юкка чыкмаячак.

**III. Йомгаклау өлеше.**

Рефлексия.

**Тәрбияче.** Безнең илдә ел саен май башында нинди бәйрәм үткәрелә? Ни өчен безнең халык Җиңү көнен бәйрәм итә? Бөек Ватан сугышы ничә ел дәвам иткән? Кем ул ветеран? Ни өчен Җиңү көнендә күпләрнең күзләре яшьләнә дип уйлыйсың?

**«Содатка хат»** Кызганычка каршы, хәзер дә илебез күген тыныч дип әйтеп булмый. Ерак җирләрдә авылдашларыбыз һәм бик күпләр тынычлык урнаштыру өчен көрәшә. Ә хәзер балалар, без сезнең белән МХО да катнашучы батырлар өчен котлау открыткалары ясап, Җиңү көне белән тәбрикләп аларга җибәреребез.

Батырлыкны эшли ала
Бөтен кеше дә.
Аның өчен кирәк түгел
Алып көче дә.
Ә моның өчен:
Яратырга кирәк бары
Туган җиреңне,
Әти — әниеңне,
Туган илеңне.

**Э.Шәрифуллина “Минем бабай”.**

*(Шигырь уку)*

*Сабирзянова Рәфинә Мөнәвир кызы*
*Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы*
*“Кырынды башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы”, тәрбияче*

**Яшь үзенчәлеге:** мәктәпкә әзерлек төркеме өчен.

**Бурычлар:**

- әдәби әсәр аша балаларда патриотик хисләр, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.

- шигырьнең эчтәлеген балаларның аңына җиткерү, шигырь буенча сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәсен камилләштерү, аларның игътибарын, хәтерен, кызыксынуын үстерү.

- балаларның бу шигырь аша Бөек Ватан сугышы геройлары турынды күзаллауларын киңәйтү, өлкәннәргә, хәрбиләр һөнәренә карата хөрмәт, шигърияткә мәхәббәт тәрбияләү.

**Максат:** Бөек Ватан сугышы чоры балаларының геройларча гамәлләре мисалында балаларда Ватанга карата патриотик хисләр формалаштыру.

**Белем бирү өлкәләре:** сөйләм үсеше, нәфис-нәфасәти үсеш, танып белү, социаль үсеш, физик үсеш.

**Эш алымнары**: аралашу, сөйләү, соауларга җаваплар бирү.

**Сүзлек эше:** Ватан, дошман, капитан, орден.

**Алдан башкарылган эш:** Бөек Ватан сугышында катнашкан балалар турында әңгәмәләр үткәрү, кинофильмнардан өзекләр карау; сугыш темасына багышланган картиналар белән таныштыру; фронт, сугыш, тыл, герой, ветеран сүзләренең мәгънәсен ачыклау.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы:**

**1.Оештыру моменты. Психологик кәеф булдыру.**

Тәрбияче:

-Исәнмесез балалар! (Исәнмесез!)

Мин сезне бүген күрүемә бик шат.

-Әйдәгез балалар, барыбызның да күңеле шат, кәефе яхшы булсын өчен бер-беребезгә хәерле көн телик. *(Тәрбияче балаларга таба кулларын сузып сәламли. Аңа карап балалар да бер-берсен сәламлиләр)*.

Бу – минем күзләр, (*кулларны бинокль итеп күзгә куялар)*, күзләр уянды, (*күзләрне бер йомалар, бер ачалар),*

Бу – минем колаклар, (*кулларны колакка куялар)*, колаклар уянды. (*башны як-якка брогалыйлар*)*,*

Бу – минем куллар, (*кулларны сыпыралар)*, куллар уянды, (*кулларны чәбәклиләр),*

Бу – минем аяклар, (*аякларны сыпыралар)*, аяклар уянды, (*аякларны тыпырдаталар),*

Без уяндык! Без уяндык! Хәерле көн сезгә! (*кулларны алга сузып бер-берсен сәламлиләр).*

**2.Актуальләштерү**.

Тәрбияче:

-Балалар, без сезнең белән үткән шөгыльләрдә 9 май, ветераннар, Җиңү көне, сугыш турында күп кенә сөйләшүләр алып бардык, шигырьләр укыдык, рәсемнәр ясадык, видеоөзекләр карадык. Бүген без шул белемнәрне дә искә алырбыз, яңаларын да өстәрбез.

**3.Төп өлеш.**

Тәрбияче:

- Балалар, тиздән безнең нинди бәйрәм җитә? (9 нчы май- Җиңү бәйрәме).

-Әйе, Җиңү бәйрәме, этиләрнең, бабайларның, абыйларның бәйрәме.

-Балалар, минем сезгә бер тарих турында сөйлисем килә. *(Тәрбияче сөйләгәндә, экранда алмашынып тема буенча слайдлар күрсәтелеп тора).*

Яшәгәннәр ди балалар. Аларның да этиләре, әниләре, әбиләре, бабалары, абыйлары һәм сеңелләре булган. Матур өйләрдә яшәгәннәр. Алар, сезнең кебек үк, балалар бакчасына йөргәннәр, башка балалар һәм тәрбиячеләр белән уйнаганнар, күңел ачканнар. Әти-әниләр белән велосипедта йөрергә, кунакка барырга яратканнар. Гаиләләре белән су коенырга йөргәннәр. Кызлар, шулай ук безнең кызлар кебек үк, курчаклар белән уйнарга ярата торган, ә малайлар машина белән комда уйнарга яратканнар, һәм үскәч, солдат булырга хыялланганнар.

Тик бервакыт, көтмәгәндә генә куркыныч афәт килеп чыга! 1941 елның 22 июнендә, гадәти җәйге көндә, сугыш башлана. Менә шулай дип игълан итәләр. *(Совет мәгълүмат бюросыннан җиткерелгән фонограмма тыңлыйлар)*. Төнлә бөтен халык йоклаганда, безнең илгә фашистлар һөҗүм итә башлый. Кешеләрнең йортлары, балалар бакчалары, мәктәпләр, заводлар, фабрикалар җимерелә башлый. Бу бик куркыныч була. Безнең бөтен халык, ир-атлар һәм хатын-кызлар, балалар һәм картлар дошманга каршы көрәшкә күтәрелә. Сугышта балалар белән тылда калган хатын-кызлар да катнаша. Алар авыл хуҗалыгында эшләп бик авыр хезмәт куялар, фронтка кирәкле корал һәм азык-төлек белән тәэмин итеп торалар. Бу барысы өчен дә, бигрәк тә кечкенә балалар өчен, бик авыр вакыт була. Балалар, өлкәннәр белән беррәттән, фронтка үз Ватанын дошманнан якларга киткән этиләрен, өлкән абыйларын һәм апаларын алмаштыралар.

Тәрбияче:

-Хәзер мин сегә Эльмира Шәрифуллинаның “Минем бабай” шигырен укыйм. Сез игътибар белән тыңлагыз. Кабат бергәләп сорауларга җаваплар эзләрбез.

Минем бабай.(Э. Шәрифуллина)

Минем бабам-капитан,
Сугышта булып кайткан.
Күкрәк тулы орденнар.
Безнең илдә һәр бала
Уйнап-көлеп йөрсен дип.
Хәвеф-хәтәр күрмәсен,
Тыныч булып үссен дип,
Көрәшкән чакта бабам,

Әни нәкъ минем яшьтә булган.

Рәсем ясап, хат язып,

Бабама салып торган.

Бик күп сугышкан бабам,

Дошманны җиңеп кайткан.

Үзе белән ул безгә

Тынычлык алып кайткан.

Тәрбияче:

-Балалар, кем турында икән бу шигырь? (Бабай турында).

-Әйе, дөрес, монда сүз бабай турында бара.

-Балалар, ә сезгә шигырь ошадымы? (Әйе, юк)

-Сез нәрсә ишеттегез һәм нәрсә аңладыгыз? (*Балалар җавап бирә)*

-Сез аңламаган нинди сүзләр очрады шигырьдә? (*Балалар кыенсынган сорауларга сүзлек эше үткәрелә)*

Тәрбияче:

-Хәзер шигырьне тагын бер кат укыйк әле. *(тәрбияче икенче тапкыр укыганда коврографка бабай, әби, әти, әни, малай, кыз рәсемнәрен куя)*.

Тәрбияче:

-Балалар, бу шигырьдәге сүзләрне кем әйтә, сез ничек уйлыйсыз? (Малай, кыз).

-Малайның, яисә кызның сугышта кеме булган? (Бабасы).

-Аның бабасы сугышта кем булган? (Капитан). *(Балалар каршына капитан бабай рәсеме эленеп куела)*

-Орден, медальләрне бабайга ни өчен биргәннәр? (*Балалар җавап бирә)*

-Бабай нинди уйлар белән сугышка кергән? (*Балалар җавап бирә)*

Тәрбияче:

-Ә көчле ир-егет, Ватанны саклаучы булыр өчен нинди булырга кирәк? Нәрсәләр эшләргә кирәк? (йөгерергә, сикерергә, үрмәләргә)

- Әйе, бик дөрес. Алар көчле, кыю, гадел, үз сүзендә тора белүче булырга тиеш.

-Ә нинди ул гадел кеше? (*Балалар җавап бирә)*

-Ә нинди ул көчле кеше? (*Балалар җавап бирә)*

-Ә нинди була ул кыю кеше? (*Балалар җавап бирә)*

-Ә нинди була ул сүзендә тора белүче кеше? (*Балалар җавап бирә)*

-Ә шигырьдәге малайның бабасы нинди булган? (*Балалар җавап бирә)*

**Ял итү вакыты.**

Тәрбияче:

Ә хәзер  бераз ял итеп алыйк. Без “Күрсәт әле үскәнем” уенын уйнап алырбыз. *(Уен барышы белән балалар инде таныш*). Уенның барышы белән сез инде таныш. Кем миңа уен барышын искә төшереп аңлатып китә? *(Бер бала уен тәртибен искә төшереп аңлатып ала*).

Күрсәт әле үскәнем, ничек йөгерәләр солдатлар?

Менә шулай, менә шулай, шулай йөгерәләр солдатлар.

Күрсәт әле үскәнем, ничек сикерәләр солдатлар?

Менә шулай, менә шулай, шулай сикерәләр солдатлар.

Күрсәт әле үскәнем, ничек үрмәлилр солдатлар?

Менә шулай, менә шулай, шулай үрмәлиләр  солдатлар.

Тәрбияче:

Булдырдыгыз, балалар.

Тәрбияче:

-Балалар,  хәзер шигырьне тагын бер тапкыр укып чыгам, тагын бер кат игътибар белән тыңлагыз.

-Җиңү безгә нәрсә китерде? (*Балалар җавап бирә).*

*(Экранда сугыш беткән көннәр турында, бүгенге тормышны чагылдырган  видеоязмалар күрсәтелә)*

-Балалар, бу инде, хәзер без яши торган тормыш.

**4. Йомгаклау өлеше.**

Тәрбияче:

- Балалар, ә кем ул герой? (Батырлык кылган кеше, кыю кеше).

Тәрбияче:

-Дөрес! Герой ул батырлык кылган, гомерен кызганмыйча, үз Ватанын, халкын яклаган кеше.

Тәрбияче:

-Балалар теләсә кайсы вакытта үз илегезне саклау өчен яхшы физик әзерлектә булырга кирәк. Спорт белән шөгыльләнү, саф һавада йөрү, дөрес туклану иң яхшы нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итәчәк. Без сезнең белән шуңа омтылырга тиешбез. Һәм без моны эшли дә алабыз.

Тәрбияче:

-Балалар, шул сугыштан кайткан һәм хәзер безнең арада яшәүче кешеләрне ничек атыйлар? (Ветераннар).

Тәрбияче**:**

-Әйе, дөрес. Без беләбез,  9 нчы май көне – ул  «Җиңү көне». Ул көнне без сезнең белән һәйкәл янына барачакбыз. Анда митинг оештырылачак. Шунда без күкрәкләренә орденнар

таккан, өлкән кешеләрне, ветераннарны күрә алабыз. Быел без Бөек Җиңүнең 80 еллык бәйрәмен каршылыйбыз. Илебез азатлыгы өчен көрәшкән солдатларны онытмаска кирәк.

Тәрбияче:

-Балалар, ә хәзер барыгызда кулга кул тотынышып түгәрәккә басыгыз, кулларыгызның җылысын бер-берегезгә бүләк итегез. Бер-берегезгә карап елмаегыз, сәламәтлек теләгез. Сез булдырдыгыз!

**Кулланылган әдәбият:**


-“Татар телендә сөйләм үстерү”: мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен методик кулланма. Төзүчеләр: Г.Ә.НӘбиуллина,Л.Г.Гыйләҗева, В.М.Камалова.

-“Туган телдә сөйләшәбез”: 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек. Төзүчеләр:З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиева,Р.С.Зөфәрова.


## «Безгә тынычлык кирәк».

(*Катанаш төркем балалары өчен эшчәнлек конспекты)*


*Васильева Фәридә Мирсәет кызы,*

*Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениесе, тәрбияче*


**Максат:** патриотик тәрбия бирү өчен шартлар тудыру.

**Үстерү бурычы:** балаларның Бөек Ватан сугышы, аны саклаучылар төшенчәләре турында аңлап сөйләү күнекмәләрен, күзаллау һәм фикерләүне үстерү.

**Тәрбия бурычы**: сугышчылар батырлыгына хөрмәт белән карарга өйрәнү, туган ягың белән кызыксыну, аның кешеләре белән горурлану хисләре тәрбияләү.

**Белем бирү бурычы**: Бөек Ватан сугышы, Җиңү бәйрәме турында белемнәрне арттыру, ерактагы сугышчыларның хәленә керә белергә өйрәтү.

**Сүзлек эше**: хәрби, батырлык, Ватан

**Җиһазлау:** сугыш тавышлары белән аудиоязма, проектор, ноутбук, экран, уртанчылар һәм зурлар төркеме балалары өчен дидактик уеннар җыелмасы, һәр балага Георгий тасмасы.

**Төп белем бирү өлкәсе**: танып белү үсеше.

**Интеграль белем бирү өлкәләре**: сөйләм үсеше, социаль-коммуникатив үсеш.

**Алдан үткәрелгән эш**: Бөек Ватан сугышы турында матур әдәбият әсәрләре уку, Тирсә авылыннан Бөек Ватан сугышында катнашучылар турында мәгълүмат эзләү һәм өйрәнү, дидактик уеннар уйнау, шигырьләр һәм җыр өйрәнү, буягычлар белән эшләү.

**Эшчәнлек төзелеше**

**I. Кереш өлеш.**

1. Исәнләшу.

2. Әңгәмә.

**II. Төп өлеш.**

1. Балалар чыгышы. «Тирсә авылыннан Бөек Ватан сугышында катнашкан батырлар»

2. Бер минутлык тынлык

3. Ял минуты. «Постта тора бер солдат».

4.Дидактик уен «Дөрес җый».

5. МХО да катнашучыларга видеохәбәр төшерү.

**III. Йомгаклау өлеше.**

**Рефлексия.**

«Тынычлык җыры»н башкару.

**Эшчәнлек барышы.**

**I. Кереш өлеш**

**Тәрбияче**. Балалар, карагыз әле, бүген көн нинди матур, кояшлы. Күрәм, сезнең дә кәефегез әйбәт. Миңа учларыгызны күрсәтегез әле. Бер-берсенә ышкып карагыз әле аларны. Нәрсә сизәсез?(*җылы*) Бу сезнең күңелегез җылысы бит. Аны күршегезгә тапшырыгыз. Безнең бакчага менә шундый яхшы балалар йөри шул. Ә хәзер күзләрне йомып тыңлыйк әле? Нәрсә ишетәсез?( *кошлар сайрый, кемдер йөри, машина тавышы килә, песи мияулый һ.б.)* Бу безнең тыныч тормышыбыз. Ә хәзер күзләрегезне ачыгыз.
( *Тәрбияче сугыш барган тавыш кабыза*) Ничек уйлыйсыз, мондый тавышларны кайда ишетергә була? (с*угышта*) Дөрес, безнең бабайлар әле кечкенә булган заманда безнең илебездә сугыш башланган. Бөтен кеше Туган илен саклап сугышкан. Һәр гаиләдән әтиләр, абыйлар, бабайлар туган илен якларга киткән. Шуңа күрә ул Бөек Ватан сугышы дип аталган. Ватан – ул безнең туган өебез, илебез. 80 ел элек батырлар дошманны җиңгәннәр.Чөнки алар үз туган илләрен, Ватаннарын саклап сугышканнар.

**II. Төп өлеш**

Безнең авылдан да күп кешеләр катнашкан. Шуларның берничәсе турында безгә балалар сөйләр. Аларның хикәясен утырып тыңлыйк.

**Ахметшин Зия Ситдикович очучы булган. Сугыш башланган төндә Латвия күгендә кинәт дошман самолетлары бомбалар ташлый башлады дип искә алган. Зия бабай техник булган һәм самолетларны тиз генә төзәтеп сугышка әзерләгән. Волхов, Белоруссия, Ленинград һәм Прибалтика фронтларында 1000 самолетка техник хезмәт күрсәткән. Батырлыгы өчен ике Кызыл Йолдыз ордены, 10 медальгә лаек булган. Сугыш беткәч, Казанда самолет төзү заводында эшләгән. Җиңү көнендә балалар белән очрашып, сугыш турында сөйли торган булган.**



**Вәлиев Фәиз Кәримович**үзенең яшенә ярты ел өстәп яздырып, 17 яшендә сугышка киткән. Зенитчик булып Украинада сугышкан. Зенитчиклар дошман самолетларын бәреп төшергәннәр. Дошманны Польшага кадәр куып барганнар. II нче дәрәҗә Ватан Сугышы ордены һәм күп медальләр белән бүләкләнгән. Сугыш беткәч, бергә сугышкан дусларын кунакка чакыра торган булган. Бөтен СССР дан аңа хатлар язганнар. Дусларының исемнәрен һәм адресларын китап итеп язып калдырган һәм оныкларына тапшырган.



**Әмиров Сәйфи Мифтахетдинович** һөнәре буенча укытучы булган. Сугышның башыннан ахырына кадәр фронтта булган. II нче дәрәҗә Ватан Сугышы ордены булган. Мәскәү, Кенигсберг, Польша өчен сугышларда катнашкан өчен күп медальләр белән бүләкләнгән. Сугыш беткәч җитәкче булып Казан Авиация институтында, Ашхабад шәһәрендә, Менделеевск химия заводларында эшләгән. Пенсиягә чыккач Казанда сугыш ветераннары оешмасын төзегән. Бик шәп гармунчы булган, ветераннар белән концертлар ясаган. Республикабыз архивын өйрәнеп, Тирсә авылы турында мәгълүмат җыеп китап чыгарган.



**Тәрбияче**. Зур рәхмәт, балалар. Туган авылыбызда шундый батыр солдатлар булу белән без горурланабыз. Аларның батырлыгын онытмыйк, искә алып бер минут тын торыйк әле.(*Бер минутлык тынлык)*

Зур үскәч, безнең малайлар да солдатка барып, үз туган илләренә бурычларын үтәрләр дип уйлыйм. Солдат турында бер уен уйнап алыйк әле.

**Ял минуты.**«Постта тора бер солдат».

Иртән иртүк, таң атканда,
Постта тора бер солдат.
Генералны күрү белән

Эшләргә кирәк шулай ( *честь бирергә)*

Иртән иртүк, таң атканда,

Постта тора бер солдат.

Тәртипсезне күрү белән

Эшләргә кирәк шулай ( *мылтыгын атарга төзи)*

Иртән иртүк, таң атканда,

Постта тора бер солдат.

Якын дустын күрү белән

Эшләргә кирәк шулай (*кул болгый)*

Иртән иртүк, таң атканда,

Постта тора бер солдат.

Пешекчене күрү белән

Эшләргә кирәк шулай (*кашык белән ашый)*

**Тәрбияче.** Әйдәгез әле без дә солдатлар кебек сугышчан транспорт төрләрен дөрес итеп җыеп исемнәрен әйтеп күрсәтик.

**Дидактик уен «Дөрес җый».**

(*Уртанчылар төркеме балалары өстәл артына килеп 2-3 кисәккә бүленгән сугышчан транспортны җыялар)*

Ә зурлар төркеме балалары бары тик хәрби солдат, танкист, сапер, очучы, чик сакчысы һ.б. өчен кирәкле предмет рәсемнәрен сайлап аңлатып бирерләр.(***Артык, кирәкмәгән рәсемнәр дә куярга мөмкин).***

**Тәрбияче.** Булдырдыгыз, балалар. Хәзер дә тормышыбыз тыныч түгел. Күпләрнең әтиләре, абыйлары махсус хәрби операциядә катнаша. Без аларга кулдан килгәнчә ярдәм итәбез. 9 нчы майда Җиңү көненә аларга бәйрәм бүләге итеп матур открыткалар ясап, күчтәнәчләр җибәрербез әле яме. Алар бит үзләрен кызганмыйча, безне яклап изге көрәшкә киттеләр. Алар хөрмәтенә без матур шигырьләр өйрәндек. Видеога төшереп җибәрсәк, кәефләре күтәрелер дип уйлыйм.

Ярый әле кыю егетләр бар,

Туган илебезне сакларга.

Уяу тора алар ил чигендә

Сатмас аны һич тә ятларга.

Ярый әле янда әтиләр бар,

Гаиләбезне якларга.

Малайлары күреп, ныгып үсә,

Ышанычын аның акларга.

Ярый әле җирдә бабайлар бар,

Хәтерләтеп сугыш елларын.

Ярый әле жирдә кыюлык бар,

Тибрәтергә йөрәк кылларын.

**III. Йомгаклау өлеше.**

**Рефлексия.**


**Тәрбияче.** Балалар, бүген нинди яңалык белдегез? Ватан нәрсә ул? Безнең бабайлар нинди сугышта булган? Бу турыда кемгә сөйләрсез? Җиңү көне кайчан була? Җиңү бәйрәме алдыннан сезгә Георгий тасмасын бүләк итәсем килә. Ул сугыштагы ут һәм янгынны чагылдыра. Илебезне саклап, безнең тыныч бәхетле киләчәгебез өчен сугышкан батырлар истәлеге итеп тагып йөрербез. Ә безгә тынычлык кирәк. Без өйрәнгән «Тынычлык җыры» шул турыда.

“Тынычлык җыры” плюсовка

https://pinkamuz.pro/search/тынычлык%20жыры

**Бөек Ватан сугышының виртуаль музее. ссылка**

https://tatfrontu.ru/personi/1?page=21&ysclid=m8miqmi78a550922405






















**Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышлана**
**“Хыялларның канатлары янды....”**

*Шәйхиева Гөлсинә Мансур кызы,*
*Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениесе, тәрбияче*

**Максат**: Баларның Җиңү бәйрәменең асылына төшендерү, аларда бәйрәм рухы тудыру, җырларны күмәк итеп, бер-берсен тыңлап җырлауны, шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйләүне ныгыту.

Балаларда патриотик хисләр, Бөек Ватан сугышы ветераннарына олылау, хөрмәт тәрбияләү.

Зал чәчәкләр һәм тасмалар белән бизәлгән. Талгын гына музыка астында ике алып баручы чыга.

**1 нче алып баручы.**

Язлар үтеп, ямьле җәйләр килде

Туган ягым күмелде чәчәккә.

41 нең җәен халык каршылый

Зур өметләр баглап киләчәккә.

Ак болытлар өерен тирбәтеп

Җылы җилләр тагын исteләр.

Кояш нуры белән бизәлешкән

Күбәләкләр очып киттеләр.

**2 нче алып баручы.**

Күкрәк киереп, гөлләр таҗын җилпи

Күрегез, күр безне, дигәндәй.

Тоелалар алар сәлам юллап,

Бер-берсенә башын игәндәй.

Шул иртәдә печән чабу өчен

Авыл халкы чыкты болынга

Күмәкләшеп, өмә ясап эшли-

Шундый гадәт борын-борыннан.

**1 нче алып баручы.**

Сызганулы кулда чалгы,

Эх, ул яшел печән исләре...

Эшкә дәрт һәм кулга дәрт бирә

Туган якны ярату хисләре.

**2 нче алып баручы:** Хәерле көн, кадерле балалар, апалар, килгән кунаклар!Хәерле көн, ветераннарыбыз!Сезнең барыгызны да бөек тантана - Бөек Җиңүнең 80 еллык бәйрәме белән котлыйбыз. Җиңү көне сезнең күңелләрдә уелып калсын өчен, кадерле балалар, сугыш эчендә булган, немец фашистларын җиңүдә көчләрен аямаган ветераннарны очрашуга чакырдык.

**1нче алып баручы :** Хөрмәтле кунаклар! Бу җиңү зур корбаннар аша килде, һәм менә бүген Бөек җиңүгә 80 ел. Сугыш вакытында халкыбыз тудырган зур батырлыклар һәм кичергән зур газаплар 80 ел буена да, 100 ел буена да онытылмаячак.

**2 нче алып баручы:**

Июнь таңы тыныч, нурлы иде,
Күкне кара сөрем каплады.
Фашизмга каршы ил кузгалды,
Барча халык утка атлады.

**1 нче алып баручы:** Дуслар! Бабай һәм әбиләрегез сезгә сугыш белән бәйле истәлекләрен сөйләгәннәре бардыр, әлбәттә. Аларның орден-медальләрен дә кулларыгыз белән тотып караганыгыз бардыр. Кайчан, ни өчен бирелгәнен дә беләсездер әле. Әйе, “сугыш” дигән куркыныч сүзне ишетү түгел, хатта ак кагәзь битенә дә язасы килми. Чөнки сугыш ул кайгы, канкоеш, бик күп корбаннар, бәхетсез ятим балалар! Быел халкыбыз Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итә. Нинди авыр булган ул сугыш еллары! Әммә ләкин халкыбыз түзгән, җаны-тәне белән дошманны җиңәргә ашкынган.

**1 бала**.:Кирәкми безгә кан кою,
Кирәкми безгә сугыш.
Безнең теләк – якты, матур,
Тыныч хезмәт һәм тормыш!

**1 нче алып баручы:** 1941 ел 22 июнь… Таң атып килә. Гүзәл авыллар, шәһәрләр тыныч йокыда. Әниләрнең җылы куенында тәмле төшләр күреп, нәни сабыйлар изрәп

йоклыйлар. Ләкин немец фашистлары, илебез халкының тыныч йокысын бүлеп, рәхимсез һәм канлы сугыш уты ачтылар. Бөек Ватан сугышы башланды. Берни белми изрәп йоклаган сабыйлар, зәңгәр күккә карап, хәрәкәтсез калдылар. Зәңгәр күкне канлы корым каплады. Бу кара һәм шомлы көннәр 1418 көн дәвам итте. Канэчкеч сугыш 50 миллион халыкны йотып, бик көттереп җиңү белән тәгәлләнде. Илебезнең ир-егетләре тиз әйләнеп кайтырбыз диделәр дә, ут эченә барып керделәр.

**2бала.:** Сезгә һич тә җиңел булмагандыр,

Үтүләре тормыш юлларын.

Озын гомер, саулык, тыныч картлык

Тели сезгә кыз һәм уллары.

**Зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балалары башкаруында җыр “Солдат булам”**

**2 нче алып баручы:** Мәскәү яны сугышларында, «Безнең артта — Мәскәү» дип, Мәскәү өчен сугыштылар. Сталинградтагы сугышларда, илне дошманга бирмәскә дип, һәр йорт өчен көрәштеләр. Тиңдәшсез зур батырлыклар күрсәттеләр. Ничәмә ничә тапкыр үлем белән күзгә-күз очраштылар, бик күпләре яу кырында ятып калдылар.

**3бала**.: Бер кайтырбыз диеп киткән юлдан

Китсәләр дә алар кайтмады.

Алар өчен бары җилләр генә

Ачып-ябып йөрде капканы.

**Түрдә һәйкәл**

**Таякка таянган, кулына чәчәк тоткан ана боек кына һәйкәл янына килә:**

- Исәнме, улым, менә мин яңадан синең янында, салкын түгелме, балакаем?

**Улы:** *(магнитофоннан акрын гына егет тавышы ишетелә)*

Юк, әнкәем, салкынның ни икәнен белмим мин. Миңа беркайчан да салкын булганы юк.

**Ана:** Нигә үзеңне сакламадың, улым? Хәтерлисеңме, җиңәрбез дә кайтырбыз дигән идең, улым?

**Улы:** Әйткән сүзләрем һәрвакыт йөрәк түрендә, әнкәем. Мин генә түгел, меңнәр, миллионнар бу көрәштә башларын салды. Картлык көнендә ничек яшисең, әнкәй?

**Ана:** Бар да җитеш, улым. Менә әби инде мин. Бәлки бик тиз генә танымагансыңдыр?

**Улы:** Таныдым, әнкәем, әллә кайлардан таныдым, күз нурым. Әгәр мөмкин булса, мин сине кочагыма алыр идем. Әмма минем кулларым да, инде үзем дә кузлы тимердән. Мәңгелек мин, әнкәем!

**Ана чәчәк сала, яшен сөртә, акрын гына атлап чыгып китә.**

**2 нче алып баручы:** Татарстаннан сугышка 560 мең кеше, шул исәптән безнең

авыл кешеләре дә фронтка китә. Бу Җиңү зур корбаннар аша килде һәм менә 80 ел инде илебез халкы тыныч тормышта яши. 4 ел сугыш дәвамында халкыбыз тудырган зур батырлык һәм кичергән зур газаплар 70 ел буена да, 100 ел буена да онытылырлык түгел. Каһарманнар даны мәңгелек!

**5 бала**.: Бәйрәмнең тагын да
Матуры, олысы.
Кояшлы май кебек
Яктысы, җылысы.
Бабамның сугышта,
Кан коеп алганы.
Зур Җиңү бәйрәме,
Дигәне бар әле!

**Җыр “Катюша”**

**1 нче алып баручы:** Сугышның беренче көннәреннән үк урысы, татары, башкорты, чуашы туган иле – Ватанын сакларга күтәрелде. Алар илебезне генә түгел, бөтен дөньяны фашизм колыннан коткарды. Сугыш авырлыгын бөтен ил, бөтен халык бердәм күтәргәнгә генә Җиңү таңын күрергә насыйп булды.

**2 нче алып баручы:** . Бер кайтмасак, бер кайтырбыз дип китсәләр дә, күпме солдат туган туфрагын күрү бәхетенә ирешә алмады. Алар еракта мәңгелек йокыга талдылар. Туган Ватаны, туган җирләре өчен башларын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк.Безнең якты киләчәгебез, сабыйларның тыныч йокысы өчен башларын салган солдатларыбызны зур хөрмәт һәм бер минут тынлык белән искә алыйк.

**7 бала**.: Матурлыгы өчен бу көннәрнең
Кемнәр генә корбан булмаган.
Исемнәрен тарих безгә үзе,
Саклап килә ерак еллардан.

**8 бала**.: Инде мин ничәнче мәртәбә
Гасырлар китабын актардым.
Күпме яу, сугышлар аркылы,
Син җиңеп чыккансың, Ватаным.

**Уен «Снайпер»**

**9 бала**.: Бик күп сугышкан бабам,
Дошманны җиңеп кайткан.
Үзе белән ул безгә,
Тынычлык алып кайткан.

**10 бала**.: Минем бабай орденнарын

Медальләрен такты бүген.

Ялт-йолт итеп тора алар,

Шуңа күрә якты бүген.

**11бала**.: Ул иң батыр солдат булган

Мин дә солдат булачакмын.

Бабам тыныч ял итсен дип,

Ил чигендә торачакмын!

**Җыр “Иң шәп бабай”**

**12бала.:** Шундый матур, бай илдә

Бик бәхетле үсәм мин.

Укып белгәч, зур үскәч

Илгә хезмәт итәм мин

**1 нче алып баручы**: Балачагын, яшьлекләрен сугыш урлаган, шулай да эштән арып кайтып, ач-ялангач килеш, су буйларында, кичке уеннарда, аулак өйләрдә күңел ачарга үзләрендә көч-дәрт тапканнар сугыш чоры яшьләре. Әйдәгез әле, әби- бабаларыбыз яшь чакларында уйнаган уеннарының берсе булган бер уенын уйнап үтик.

**Муз. уен: “Чума үрдәк, чума каз”**

**1 нче алып баручы:** 80 ел элек безнең бабаларыбыз тынычлык өчен кан койганнар.Безнең халык тынынчлык һәм тыныч тормышның бәясен белә. Җирдә халык матур яшәсен өчен-тынычлык кирәк. Ә тынычлык нәрсә соң ул:

Тынычлык ул-кояшлы иртә

Тынычлык ул-синең көндәлек шөгелең

Тынычлык ул-сары иген басулары һәм чәчәкле кырлар

Тынычлык ул-балалар бакчасы һәм мәктәпнең ишеге ачык булу

Тынычлык ул-синең янәшәңдә булган әти һәм әниең.

**2 нче алып баручы:** Хөрмәтле кунаклар, тыл ветераннары, балалар! Бәйрәмебез ахрына якынлаша. Бу гадәти бәйрәм түгел. Ул күз яшьләренә манчылган. Сугыш афәте беркайчан да илебез күген капламасын! Җир йөзендә мәңге тынычлык булсын дибез . Күп еллар безгә шушындый очрашулар насыйп булсын!

Бүгенгенең матур хәтирәсе

Күңелләрдә калсын уелып.

Истәлекне яңартырбыз бергә,

Җиңү язы килгәч, җыелып.

Әкрен генә **“День Победы “ җыры уйнатыла.**

**Батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм дүрт тапкыр Бөек Ватан сугышы ордены, күп медальләр белән бүләкләнгән шагыйрь Шиһабетдин Садыйков истәлегенә.**

***(Ата-аналар, укытучылар һәм тәрбиячеләр өчен)***

*Ләйсирә Наил кызы Юсупова*
*Ижау шәһәре, 107 нче балалар бакчасы тәрбиячесе.*

**Шиһабетдин Садыйков**

*"Әйе, мин тормышны өзелеп яратам.*
*Шул бөек хис, бәлки каты сугышлардан*
*да исән чыгуыма сәбәпче булгандыр,*
*соңрак ак кәгазь битләренә берәм-берәм*
*энҗе бөртекләредәй тезелгән иҗат*
*җимешләремнең дөньяга туууына да*
*этәргеч ясагандыр".*
*Шиһабетдин Садыйков. 2005 ел.*

Шиһабетдин Садыйков 1923 нче елның 1 ноябрендә Әгерҗе районы Ямурза авылында дөньяга килә.

Бер әнидән сигез бала
Тудык якты дөньяга.
Биш ир бала, өч сеңлекәш
Үстек бер йортта буйга,- дип яза ул "Сигез бала" шигырендә. Шиһабетдин ир балалар арсында иң кечесе- бишенчесе була. Әкияти гүзәллеккә ия булган авылда нарат, каен урманнарында җиләк, гөмбәсен җыеп, бормаланып аккан инеш суларында коенып үскән ул. Хезмәт юлы 15 яшеннән башланып китә. Укытучы булып эшли. Әмма Бөек Ватан сугышы башланып, Шиһабетдин 18 яшендә туган нигезен, якыннарын калдырып, илне сакларга чыгып китә. Ул 1942 нче елның 9 мае була. "Яшьлегем төштә күргән кебек кенә, бер назлы мизгел сыман..."-дип искә ала ул.

Сугыш авыр, дошман явыз. "Сугыш бетеп, исән калсам, башта туйганчы бер утырып ашар идем, аннан йоклар идем, - дип хыяллана егет яу кырында. Өч елдан артык сугышның иң алгы сызыгында башта пулеметчы, аннан бүлек, взвод командиры була. Батыр сугышчы, шул еллар эчендә өч тапкыр яралана, ике тапкыр контузия ала. "Шунысы бәхәссез- үлеп калганнарның һәм исәннәрнең якты истәлекләренә кара тап төшерергә беркемнең дә хакы юк"-дип яза ул бер истәлегендә.

...Сугышның законы катгый-

Ут белән ут сүндерә.

Бүре булып улый сугыш,

Үгез булып үкерә.

Дүрт ел буе күпне күрдек,

Җәфа, газап кичердек.

Тик дошманга баш имәдек,

Биргән антны үтәдек... (Безнең яшьлек" шигыре)

1945 елның 9 июнендә туган ягы Ямурзага Шиһабетдин икенче группа сугыш инвалиды булып әйләнеп кайта. "Бертуган абыем Низамбетдин белән күрешүләр, аннан авылдашларым белән очрашулар – тормышымның иң бәхетле минутлар шулар булгандыр, мөгаен"...

...Ак пароход гудок биреп

Кайту хәбәрен сала.

Җәйге ал таң нурын сибеп,

Елмаеп балкып ата.

Үзем карыйм,үзем елыйм,

Пароход җитә ярга.

Мин нинди бәхеткә ия,

Туган илкәем бар да... ("Кайту" шигыре)

Фронттан кайткан авылдашлары белән бергә, җиң сызганып, бөлгенлеккә төшкән авылын күтәрү, ныгыту эшенә керешә Шиһабетдин. Ямурза авыл советы рәисе итеп билгеләнә. Һәр эшне җиренә җиткереп башкаруы, төгәл, җитез булуы белән башкалардан аерылып тора сугыш батыры. 1948 нче елда Красный Бор районы партия комитетына пропагандист итеп эшкә алалар. Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. Максим Горький исемендәге колхозга рәис итеп билгеләнә.

1959 нчы елда авылда электр станциясе төзелә. Һәр йортны, терлек торакларын утлы итүдә Шиһабетдин Садыйковның өлеше зур. Радио кертелә, кино күрсәтү җайланмасын булдырып, колхозчыларга бушлай кино күрсәтүне оештырып җибәрә. Унбер ел җитәкче булып эшләгәннән соң Казан авыл хуҗалыгы институтында белем алып кайта һәм Ленин исемендәге колхозга рәис итеп сайланыла. Өч ел дәвамында күңел биреп, яратып башкара ул бу эшне.

1967 елда язмыш аны Ижау шәһәренә алып килә. Удмуртия кулланучылар җәмгыяте автобазасына директор итеп билгеләнә. Өч елдан соң шәһәрнең Үзәк базарына директор булып урнаша. Алты ел хезмәт куйганнан соң лаеклы ялга китә. Тик хезмәт юлы моның белән генә чикләнми әле. "Ижмаш" заводында социалистик милекне саклау бүлегендә

унике ел хезмәт куя. Шулай итеп Шиһабетдин Садыйков илле еллык стажы белән алтмыш биш яшендә, чынлап лаеклы ялга чыга.

“Миңа җитмеш яшь тулып килгәндә, бәхетемә хуш килеп, Удмуртиядә “Яңарыш” газетасы дөнья күрә башлады”,-дип яза ул. “Яңарыш” ның беренче санынннан ук аның актив хәбәрчесе була. Газетада шигырьләре бер-бер артлы басылып, җитмеш сигез яшендә, 2000 нче елда тәүге “Рәхмәт сиңа, тормыш” китабын бастыру хокукына ирешә. 2005 нче елда икенче “Сугыш елларым, гомер юлларым” китабы, аннан ике ел үтүгә “Бәхетем юлдаш булгач” диеп исемләнгән өченче җыентыгы дөнья күрә.

Гомере буе якты нияттә, ак өметтә булып яши. Һәрбер эшне җиренә җиткереп башкара, милләтен якын күрә, башкаларны хөрмәт итә. Шуңа күрә аның үзен дә хөрмәт итәләр. Тик Шиһабетдин Садыйковның гомер сәгате 2021 елның 28 нче июнендә туктый. Бу көнне без яшьлеген Ватан өчен, тынычлык өчен барган көрәштә сугыш кырларында калдырган, сугыштан соңгы авыр елларда туган авылында, туган районында хезмәт куеп, гомерен, сәламәтлеген кызганмаган зур ихтирамга лаек шәхес белән хушлаштык. Бүген аны юксынганда китапларын кулга алабыз, шигырьләрен укып юанабыз. “Дөнья күргән китапларым укучыларыбызның күңелләренә хуш киләчәгенә ихластан ышанам,”- дип язып калдыра ул.

Газиз илгә, туган җиргә
Тугры булдым гомергә
Китабым да бүләк булсын
Сөекле милләтемә.

Кулланылган әдәбият:


1. Шиһабетдин Садыйков “Рәхмәт сиңа, тормыш” Ижевский полиграфкомбинат, Воткинское шоссе , 180.1999 г
2. Шиһабетдин Садыйков “Сугыш елларым, гомер юлларым” ГУП УР “Ижевская республиканская типография, ул. Пастухова, 13. 2005 г.

**Батырлыгы өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм дүрт тапкыр Бөек Ватан сугышы ордены, күп медальләр белән бүләкләнгән шагыйрь Шиһабетдин Садыйков истәлегенә.**

***(Ата-аналар, укытучылар һәм тәрбиячеләр өчен)***

*Ләйсирә Наил кызы Юсупова*
*Ижау шәһәре, 107 нче балалар бакчасы, тәрбияче.*

**Шиһабетдин Садыйков**

*"Әйе, мин тормышны өзелеп яратам.*
*Шул бөек хис, бәлки каты сугышлардан*
*да исән чыгуыма сәбәпче булгандыр,*
*соңрак ак кәгазь битләренә берәм-берәм*
*энҗе бөртекләредәй тезелгән иҗат*
*җимешләремнең дөньяга тууына да*
*этәргеч ясагандыр".*
*Шиһабетдин Садыйков. 2005 ел.*

Шиһабетдин Садыйков 1923 нче елның 1 нояберендә Әгерҗе районы Ямурза авылында дөньяга килә.

Бер әнидән сигез бала
Тудык якты дөньяга.
Биш ир бала, өч сеңлекәш
Үстек бер йортта буйга,- дип яза ул "Сигез бала" шигырендә. Шиһабетдин ир балалар арсында иң кечесе- бишенчесе була. Әкияти гүзәллеккә ия булган авылда нарат, каен урманнарында җиләк, гөмбәсен җыеп, бормаланып аккан инеш суларында коенып үскән ул. Хезмәт юлы 15 яшеннән башланып китә. Укытучы булып эшли. Әмма Бөек Ватан сугышы башланып, Шиһабетдин 18 яшендә туган нигезен, якыннарын калдырып, илне сакларга чыгып китә. Ул 1942 нче елның 9 мае була. "Яшьлегем төштә күргән кебек кенә, бер назлы мизгел сыман..."-дип искә ала ул.

Сугыш авыр, дошман явыз. "Сугыш бетеп, исән калсам, башта туйганчы бер утырып ашар идем, аннан йоклар идем, - дип хыяллана егет яу кырында. Өч елдан артык сугышның иң алгы сызыгында башта пулеметчы, аннан бүлек, взвод командиры була. Батыр сугышчы, шул еллар эчендә өч тапкыр яралана, ике тапкыр контузия ала. "Шунысы бәхәссез- үлеп калганнарның һәм исәннәрнең якты истәлекләренә кара тап төшерергә беркемнең дә хакы юк"-дип яза ул бер истәлегендә.

...Сугышның законы катгый-
Ут белән ут сүндерә.

Бүре булып улый сугыш,

Үгез булып үкерә.

Дүрт ел буе күпне күрдек,

Җәфа, газап кичердек.

Тик дошманга баш имәдек,

Биргән антны үтәдек... (Безнең яшьлек” шигыре)

1945 елның 9 июнендә туган ягы Ямурзага Шиһабетдин икенче группа сугыш инвалиды булып әйләнеп кайта. “Бертуган абыем Низамбетдин белән күрешүләр, аннан авылдашларым белән очрашулар – тормышымның иң бәхетле минутлар шулар булгандыр, мөгаен”...

...Ак пароход гудок биреп

Кайту хәбәрен сала.

Җәйге ал таң нурын сибеп,

Елмаеп балкып ата.

Үзем карыйм,үзем елыйм,

Пароход җитә ярга.

Мин нинди бәхеткә ия,

Туган илкәем бар да... (“Кайту” шигыре)

Фронттан кайткан авылдашлары белән бергә, җиң сызганып, бөлгенлеккә төшкән авылын күтәрү, ныгыту эшенә керешә Шиһабетдин. Ямурза авыл советы рәисе итеп билгеләнә. Һәр эшне җиренә җиткереп башкаруы, төгәл, җитез булуы белән башкалардан аерылып тора сугыш батыры. 1948 нче елда Красный Бор районы партия комитетына пропагандист итеп эшкә алалар. Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. Максим Горький исемендәге колхозга рәис итеп билгеләнә.

1959 нчы елда авылда электр станциясе төзелә. Һәр йортны, терлек торакларын утлы итүдә Шиһабетдин Садыйковның өлеше зур. Радио кертелә, кино күрсәтү җайланмасын булдырып, колхозчыларга бушлай кино күрсәтүне оештырып җибәрә. Унбер ел җитәкче булып эшләгәннән соң Казан авыл хуҗалыгы институтында белем алып кайта һәм Ленин исемендәге колхозга рәис итеп сайланыла. Өч ел дәвамында күңел биреп, яратып башкара ул бу эшне.

1967 елда язмыш аны Ижау шәһәренә алып килә. Удмуртия кулланучылар җәмгыяте автобазасына директор итеп билгеләнә. Өч елдан соң шәһәрнең Үзәк базарына директор булып урнаша. Алты ел хезмәт куйганнан соң лаеклы ялга китә. Тик хезмәт юлы моның белән генә чикләнми әле. “Ижмаш” заводында социалистик милекне саклау бүлегендә унике ел хезмәт куя. Шулай итеп Шиһабетдин Садыйков илле еллык стажы белән алтмыш биш яшендә, чынлап лаеклы ялга чыга.

“Миңа җитмеш яшь тулып килгәндә, бәхетемә хуш килеп, Удмуртиядә “Яңарыш” газетасы дөнья күрә башлады”,-дип яза ул. “Яңарыш” ның беренче санынннан ук аның актив хәбәрчесе була. Газетада шигырьләре бер-бер артлы басылып, җитмеш сигез яшендә, 2000 нче елда тәүге “Рәхмәт сиңа, тормыш” китабын бастыру хокукына ирешә. 2005 нче елда икенче “Сугыш елларым, гомер юлларым” китабы, аннан ике ел үтүгә “Бәхетем юлдаш булгач” диеп исемләнгән өченче җыентыгы дөнья күрә.

Гомере буе якты нияттә, ак өметтә булып яши. Һәрбер эшне җиренә җиткереп башкара, милләтен якын күрә, башкаларны хөрмәт итә. Шуңа күрә аның үзен дә хөрмәт итәләр. Тик Шиһабетдин Садыйковның гомер сәгате 2021 елның 28 нче июнендә туктый. Бу көнне без яшьлеген Ватан өчен, тынычлык өчен барган көрәштә сугыш кырларында калдырган, сугыштан соңгы авыр елларда туган авылында, туган районында хезмәт куеп, гомерен, сәламәтлеген кызганмаган зур ихтирамга лаек шәхес белән хушлаштык. Бүген аны юксынганда китапларын кулга алабыз, шигырьләрен укып юанабыз. “Дөнья күргән китапларым укучыларыбызның күңелләренә хуш киләчәгенә ихластан ышанам,”- дип язып калдыра ул.

Газиз илгә, туган җиргә
Тугры булдым гомергә
Китабым да бүләк булсын
Сөекле милләтемә.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Шиһабетдин Садыйков “Рәхмәт сиңа, тормыш” Ижевский полиграфкомбинат, Воткинское шоссе , 180.1999 г
2. Шиһабетдин Садыйков “Сугыш елларым, гомер юлларым” ГУП УР “Ижевская республиканская типография, ул. Пастухова, 13. 2005 г.


**Ватанны саклаучылар елына багышланган спорт күңел ачу кичәсе.**


*Ягьфәрова Гөлназ Гамир кызы,*
*Тирсә авылы “Миләүшә” балалар бакчасы муниципаль*
*бюджет мәктәпкәчә белем бирү дәүләт учреждениесе,*
*физкультура буенча инструкторы.*


**Максат:** Балаларда Ватанга мәхәббәт, Ватан сакчыларына хөрмәт, илгә хезмәт итүгә омтылыш тәрбияләү; җитезлекне,чыдамлыкны,көчне үстерү.

**Катнашалар: әтиләр, балалар,** алып баручы (тәрбияче)

**Җиһазлар**: погоннар, 2 картон, тоннелҗ, 4 обруч, 2 скамейка, 2 уенчык автомат, 2 костюм, 2 пилотка, 2 кечкенә туп, 2 уенчык танк, кеглялар

**Барышы.**

*Зал бәйрәмчә бизәлгән. Балалар Совет амиясе маршы көенә атлап керәләр.*

**Тәрбияче.** Хәерле кич хөрмәтле әтиләр, кадерле балалар, кунаклар! Без бүген сезнең белән бергәләп ял кичәсенә жыйналдык. 2025 ел Ватанны саклаучылар һәм Бөек җиңүнең 80 еллыгы буларак билгеләп үтелә. Бабайлар, әтиләр без тыныч, мул тормышта яшәсен, бәхетле булсын өчен Ватаныбызны саклаган. Аларга алмашка безнең дә малайларыбыз үсеп килә.

Әтиләр бабайлар, булачак солдатлар - малайларыбыз сезне барыгызны да бу бәйрәмнәр белән чын куңелдән котлыйбыз. Сәламәтлек, гаилә бэхете, шатлык телибез. Күкләребез аяз, елларыбыз имин булсын. Жыр, шигырь, уеннар белән үрелеп баручы бәйрәм кичәбезне башлап жибәрәбез.

Ә хәзер кичәбезне башлап җибәрик.

**1нче бала:**

Минем әти дә күптән
Солдатта хезмәт иткән
Әле егет чагында
Торган Ватан сагында.
Үскәч, солдат булырмын
Әтием кебек мин дә.
Турникта ул атынган
Канатта ул тартылган
Һәм күтәргән гер дә ул
Көчле шуңа күрә ул.

**2 нче бала**:

Минем абый солдатта-
Ул анда тора сакта.
Ул ант биргән Ватанга,
Аны уяу сакларга.
Бабай да солдат булган,
Әти дә солдат булган,
Зур абый да солдат булып,
Ил чикләрендә тора
Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына.
Мин үзем дә солдат булам,
Үсим әле аз гына.

**3 нче бала:**

Бүген бездэ олы бэйрэм

Ир егетләр бәйрәме.

Әтиләрне – балаларны ярыштырып

Көчне сынашыйк әле.

Сәламәтлек – зур байлык бит

Хәрәкәттә-бәрәкәт

Спорт белэн шөгыльләнү

Жанга – ял, тәнгә- рәхәт..

Килгәннәр безгә кунаклар

Тезелдек үзебез дә

Йөгерик тә, узышыйк та

Ярышлар бүген бездә.

***Җыр: "Солдат булам". (****Әлфия Һадиева көе,Айдар Минһаҗев сүз.)*

**4 нче бала.**

Туган илем имин булса,

Ал чәчәкләр үсәрләр.

Бакчаларда алмалар

Кызарышып пешәрләр.

**5 нче бала.**

Озакламый егет булып

Үсеп житәрбез әле,

Татарстан дәүләтенә

Хезмәт итәрбез эле.

***Бию: "Пилотлар"***

*Әтиләр һәм балаларны ике төркемгә бүлү. Командаларның исеме: "Танкистлар" һәм "Чик сакчылары"*.

**Тәрбияче.** Ярышыбызны башлап җибәргәнче, башта **"Сугышчан әзерлекне**" тикшерик.

*(Бубен тавышына командалар урыннарында йөгерәләр, бубенның тавышы әкеренәйгәч, атлап торалар.)*

**Тәрбияче.** Балалар, армия сафларында хезмәт итү өчен нинди сыйфатлар кирәк? *(Балаларның җавабы)*Дөрес җавап бирдегез.

Бәйгеләрне башлап җибәрәбез, командаларның үз урыннарын алуларын сорыйбыз.

**1 нче бәйге: “Погоннар”.**

*Һәр катнашучының җилкәсенә погоннар куела. Погоннарны төшермичә фишканы әйләнеп килергә, погонны алдагы катнашучыга бирергә. Бәйгене әтиләр башлап җибәрә. “Әти – бала” дәвам итәләр.*

**Тәрбияче.** Булдырдыгыз. Әфәрин, погоннарны югалтмыйча үз урыннарына кайтардыгыз.

**2 нче бәйге. “Диверсантлар”**

*Һәр катнашучы биремнәрне үтәргә тиеш.*

1. *Дуга астыннан миналарга эләкмичә генә шуышып чыгарга.*
2. *Скамейкадан дурт аяклап барырга.*
3. *Куб аша аркылы чыгарга.*
4. *Граната белән (кечкенә туп) танкка атарга.*
5. *Кире командага кайтырга.*

**Тәрбияче.** Булдырдыгыз. Әфәрин, командалар биремнәрне үтәделәр.



**3 нче бәйге. “Тревога”.**

*Урындыкларга пилотка, военный костюм, автомат куелган. Катнашучылар киенәләр һәм фишканы әйләнеп килеп,эстафетаны киләсе катнашучыга тапшыралар. Кайсы команда биремне тизрәк үти шул җиңүче.*

**Тәрбияче.** Булдырдыгыз. 3 нче бәйгенедә уңышлы гына җиңеп чыктыгыз.

***Музыкаль тәнәфес. Бию “Тынычлык кирәк җиргә”***

**Тәрбияче.** Ял итеп алдык. Инде көч сынашуны дәвам итик.

**4 нче бәйге. “Коткаручылар”.**

*Залның ике ягында идәндә обручлар ята. Шуның берсендә балалар. Әтиләр обручлар арасына бүленеп басалар. Команда буенча әтиләр 1 баланы алып кулдан кулга биреп икенче обручка бастыралар. Һәр баланы шулай күчереп бетерәләр. Кайсы команда биремне тизрәк үти шул җиңүче.*

**Тәрбияче.** Коткаручыларга, әфәрин!

**5 нче бәйге. “Кырны миналардан арындыр”.**

*Балалар бер минут эчендә, бәйләнгән күз белән, миналарны (кегляларны) җыя.*

*Командаларның җыйган миналар (кеглялар) санала. Кем күбрәк җыя шул җиңүче.*

**Тәрбияче.** Кырны миналардан арындырдык. Хәзер инде алга барыргада була.

**Тәрбияче.**

Ярыш бүген, ярыш бүген

Шундый кызык, куңелле

Ник чыкмаска ярышырга

Әллә безнең әтиләр егет түгелме!?

*Балалар бераз ял итеп торган арада, әтиләрне уйнатып алыйк әле. Рәхим итегез*

**6 нчы бәйге. “Туп тибеп фишканы әйләнеп узарга”.**

**Тәрбияче.** Әфәрин, әтиләр!

**7 нче бәйге. «Сазлык аша чыгу»**

*Һәр командага икешәр катыргы бирелә. Шуларны аяк астына чиратлап куеп фишкага кадәр бару, килгәндә кулга тотып килү.*

***Музыкаль тәнәфес. Җыр “Катюша”- “Зәйтүнәкәй”.***

**Тәрбияче.**

Бәйрәмебез гөрләп барсын,

Уен-көлке күп булсын.

Әйдәгез,егетләр ярышка,

Кызларыбыз карап торсын.

**8 нче бәйге.”*Каршылыкларны җиңү.”***

*Башта скамейкадан шуышып бару, аннан тоннельдән шуышып чыгу, обручлардан сикеру. Кире- йөгереп кенә кайталар. Беренчерәк тәмамлаган команда җиңүче.*

**Тәрбияче.**

Зур шатлык күңелебездә

Ал кояш күгебездә

Барыгыз да беләсездер

Әтиләр,бабайлар көне бездә!

***Музыкаль тәнәфес. Җыр: “Иң шәп бабай”. (****Рөстәм Сәрваров көе, Рөстәм Бакиров сүзләре)*

**Тәрбияче.**Армиядә хезмәт иткәндә төрле хәлләр булырга мөмкин. Шуңа күрә беренче ярдәм күрсәтергә дә әзер булырга кирәк.

**9 нчы бәйге. “Хәрби табиб”**

*Яралы солдатны бәйләү. Катнашучылар берәмләп килеп яралының ярасын (башын,кулын,аягын ...) бәйләп китәләр.*

**Тәрбияче.** Әйе, армиядә хезмәт итү – мактаулы бурыч. Һәр малай чын ир кеше, Ватанны саклаучы булыр өчен кечкенәдән тырышырга тиеш.

**10 нчы бәйге. “Бомбардировщиклар”.**

20-30 кабартылган шарларны, хаотик рәвештә идәнгә чәчәргә. Музыка уйнаганда катнашучылар самолет сүрәтләргә, музыка туктау белән шарны утырып шартлатырга тиешләр. Кайсы команда кубрәк шартлата, шул җиңүче.

**Тәрбияче.** Әйе, балалар, сез үзегезне бик җитез, уңган, тырыш итеп күрсәттегез. Киләчәккә бик мөһим адым ясадыгыз.Ярышыбыз ахырына якынлашты, әтиләребез, малайларыбыз сезне тагын бер тапкыр Ватанны саклаучылар елы белән тәбрик итәбез.

**Кыз бала.**

Безнең төркем малайлары
Бүген бәйрәм итәләр,
Үсеп,яшьләре җиткәч тә,
Армиягә китәрләр.
Батыр,таза егетләрне
Хөрмәт итә һәр кеше.
Бәйрәм белән тәбриклибез
Сезнең һәрберегезне.

*Кызлар малайларны бүләкли. Ярышка нәтиҗә ясала.*